МЕТОДИК ӘСБАП

# ӘДӘБИ УКУ

# 4

Г.Н.Мөхәрләмова, Д.М.Абдуллина



Г.Н.Мөхәрләмова, Д.М.Абдуллина

# ӘДӘБИ УКУ

## МЕТОДИК ӘСБАП

4

Башлангыч гомуми белем бирү оешмаларында
татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар белән
эшләүче укытучылар өчен

Казан
2023

УДК 82 (072)
ББК 74.268.3 (=632.3)
М92

Методик әсбап
Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең
Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият
һәм сәнгать институтында эшләнде

**Мөхәрләмова Г.Н.**

М92 Әдәби уку. 4 нче сыйныф. Методик әсбап : Башлангыч гомуми белем бирү оешмаларында татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар белән эшләүче укытучылар өчен / Г.Н. Мөхәрләмова, Д.М. Абдуллина. — Казан: Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе нәшрияты, 2023. — 86 б.

Методик әсбапта 4 нче сыйныфта «Туган телдә (татар телендә) әдәби уку» предметы буенча дәреслек белән эшләү тәртибе яктыртыла. Биредә предметны өйрәнүгә куелган максат-бурычлар, предметны өйрәнүдә планлаштырылган нәтиҗәләр, тематик планлаштыру, дәрес эшкәртмәләренең үрнәкләре бирелә.

Әсбап башлангыч сыйныф укытучыларына ярдәмлек буларак тәкъдим ителә.

© Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе, 2023
© Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты, 2023
© Мөхәрләмова Г.Н., Абдуллина Д.М., 2023

# ХӨРМӘТЛЕ ХЕЗМӘТТӘШЕБЕЗ!

4 нче сыйныф дәреслеге алдагы сыйныфларда өйрәнелгәннәрнең үстерелешле дәвамы булып тора. Әлеге методик ярдәмлек дәреслек белән эшләүне беркадәр җиңеләйтү, юнәлеш бирү максаты белән әзерләнде.

4 нче сыйныф дәреслеге укучыга төп һәм урта мәктәп программасын үзләштерүгә күчү өчен җирлек әзерли. Укучы халык авыз иҗаты, авторлар әсәрләре арасындагы аерманы тирәнрәк билгели ала. Аларның һәр икесенең жанрларын таный, беркадәр һәр жанрга хас үзенчәлекләрне дә аера. Әдәби әсәрне сәнгать әсәре буларак кабул итәргә һәм анализларга өйрәнә. Әсәрне мөстәкыйль үзләштерә, аның чынбарлык белән бәйләнешен ачыклый, бу хакта үз фикерен белдерә. Укучыларның әдәбият турындагы белемнәре системалаша бара. Алар алдагы сыйныфларда күләмле әсәрне кабул итәргә әзер булырга тиеш. Шуны истә тотып, текст белән эшләү һәр дәреснең төп бурычларыннан берсе булып тора. Укучының текстны тулысынча аңлап кабул итүенә ирешү өчен, төрле алымнардан файдаланырга мөмкин: әсәр эчтәлегенә карата ясалган рәсемнәр, әсәрнең исеме белән танышып, аның эчтәлеген фаразлау, абзацлап уку, һәр абзацның яңалыгына игътибар итү, алар арасында бәйләнеш урнаштыру, әсәрне укыганда, иң кызыклы урында туктап, сораулар ярдәмендә фикерләшү, текстка бәйле сораулар бирү, проблемалы сораулар әзерләү, әдәби герой исеменнән сөйләү, план төзү, план буенча эчтәлекне сөйләү.

Шулай ук укучыны әдәби әсәрне укырга, аны тулысынча аңларга җәлеп итү өчен, рольләргә бүлеп уку, сәхнәләштерү, сүз белән «рәсем ясау», рәсем ясау һәм аны шәрехләү кебек эшләр тәкъдим итәргә була.

Укучыларны укырга җәлеп итү, текст белән эшләргә өйрәтү беренчел максат булса, сәнгатьле итеп укырга өйрәтү дә зур әһәмияткә ия. Укыганда дөрес интонация, темп, логик паузаларны саклый белү, дөрес уку техникасын булдыру сөйләмне формалаштыра, зәвык тәрбияли. Үсеп килүче буынга әдәбият дәресләре бирә

алган кыйммәтле тәҗрибә һәм тәрбиянең роле гаять зур. Укучыны китапка якынайту, аны үз теләге белән укырга, укудан ләззәт алырга өйрәтү әдәби уку дәресләренең төп бурычы булып тора.

«Туган телдә (татар телендә) әдәби уку» предметын 2 сәгать укыту мөмкинлеге булган очракта тәкъдим ителгән темалар икешәр сәгать өйрәнелә. Дәреслектә өстәмә материал бар.

«Туган телдә (татар телендә) әдәби уку» предметының төп **максаты** – татар мәдәниятенең мөһим өлеше булган туган (татар) телдәге әдәбиятка сакчыл мөнәсәбәт тәрбияләү, укучыларның мәдәни мираска, үз халкының гореф-гадәтләренә тартылуын тәэмин итү, киләчәктә куелган уку бурычыннан чыгып, шулай ук үзләре кызыксынган өлкәгә караган әсәрләрне китапханәләрдән мөстәкыйль рәвештә сайлап алырлык грамоталы укучы формалаштыру.

Максатларны тормышка ашыру түбәндәге бурычларны хәл итә:

- укуга һәм китапка карата кызыксыну тәрбияләү, укучының тормышны күзаллавын формалаштыру;
- укучыларның аралашу (коммуникатив) сәләтен булдыру;
- укучыларның туган (татар) телендә телдән һәм язма диалогик, монологик сөйләмен үстерү;
- кычкырып һәм эчтән (үз-үзеңә) уку техникасын булдыру һәм камилләштерү, текстны төшенү (кабул итү һәм аңлау) алымнарын үстерү, эшчәнлекнең универсаль төрләренә – күзәтүгә, чагыштырма анализга өйрәтү;
- әдәби анализ элементларын куллану аша укучыларны сүз сәнгатенә, туган телдәге әдәбиятка якынайту, аерым әдәбитеоретик төшенчәләр белән таныштыру;
- укучыларның әхлакый һәм эстетик хисләрен формалаштыру, әсәрләрнең рухи асылын аңларга өйрәтү;
- туган (татар) телендә иҗади эшчәнлек сәләтләрен үстерү.

Укыту барышында сыйныфларда белем бирү эчтәлеге түбәндәге эшчәнлек төрләре белән үрелеп бара.

**Тыңлау.** Укытучы һәм сыйныфташлары тарафыннан кычкырып укылган текстны, әңгәмәдәшләренең фикерләрен, үзенә бирелгән сорауларны аңлау. Әйтелгән (ишеткән) сүзнең мәгънәсенә төшенү:

фикер алышу аспектын тотып алу, сөйләм эчтәлеге нигезендә сорауларга җавап бирү һәм үз сорауларыңны формалаштыру.

**Кычкырып уку.** Иҗекләп укудан сүз белән укуга күчү, уку тизлеген акрынлап арттыру. Рольләргә бүлеп уку, чылбыр буенча уку барышында кычкырып уку техникасын формалаштыру. Сәнгатьле уку үзенчәлекләрен үзләштерү (башлангыч этапта җөмләләрне тыныш билгеләренә карап, интонацион буыннарга аерып, дөрес итеп, жанр таләпләренә туры китереп уку).

**Үзлегеннән уку (эчтән уку).** Күләме зур булмаган текстны мөстәкыйль уку. Өйрәнелә торган текстта кирәкле мәгълүматларны, аңлашылмаган сүзне сүзлектән табу һәм сайлап уку ярдәмендә төп мәгънәне истә калдыру.

**Сөйләү.** Монологик сөйләм төрләрен үзләштерү: сорауга кыска яисә киңәйтелгән җавап рәвешендә; текстны укудан туган үз тәэсирләрен, тормышны күзәтүләреннән туган тәҗрибәне тапшыру рәвешендә; фикерне текстка таянып дәлилләү рәвешендә (текстта кирәкле урынны табып уку). Диалогик аралашу үзенчәлекләрен үзләштерү: әңгәмәдәшенең әйткәннәрен тыңлый һәм аларга карата үз мөнәсәбәтен белдерә белү (ризалашу / килешмәү). Текст эчтәлегенә таянып, үз фикерләрен дәлилләп яклый белү.

**Язу.** Текст төрләренең аермасын тану (текст-хикәяләү, текст-тасвирлау, текст-фикер йөртү) һәм аларны кечкенә сочинениеләр формасында практик үзләштерү; шәхси күзәтүләр һәм тәэсирләр нигезендә кыска сочинениеләр язу.

**Әдәби әсәр тексты белән эшләү.** Текстның исемен анализлау, сораулар һәм биремнәр системасы аша текстны тикшерү, төп эмоциональ-мәгънәви берәмлекләрне ачыклау (төп фикер, лирик шигырьдә төп кичерешләр, геройларның капма-каршы позицияләре һәм хикәядә автор нәтиҗәсе). Текст төзелешенең үзенчәлекләрен билгеләү, тел-сурәтләү чараларын ачыклау (антонимнар, синонимнар, сынландыру, чагыштыру). Геройның холкын билгели белү (сүз ярдәмендә тудырылган портреты аша, гамәлләрен анализлаудан, сөйләм үзенчәлегеннән чыгып, автор аңлатмалары ярдәмендә), башка геройларның үз-үзләрен тотышына чагыштырма анализ, укытучы ярдәмендә проза әсәр-

ләрендә автор позициясен һәм лирик әсәрләрдә автор кичерешләрен таба белү. Текст белән эшләгәндә, төрле сюжет сызыкларын аерып чыгара белү; эчтәлек ярдәмендә карашлар һәм позицияләрнең төрлелеген күрергә өйрәнү; сюжет үстерелешендә һәм геройларның эш-гамәлләрендә сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләре урнаштыру; автор фикерен аңлау; текстның төп фикерен аерып чыгару; тел-сурәтләү чараларын табу.

**Балалар өчен әсәрләр.** Халык авыз иҗаты әсәрләре. Фольклорның кече жанрлары (санамышлар, табышмаклар, эндәшләр); халык әкиятләре (хайваннар турында әкиятләр, көнкүреш әкиятләре, тылсымлы әкиятләр); мәкальләр һәм әйтемнәр, мәзәкләр. Автор әкиятләре, мәсәлләре, авторларның әдәби әсәрләре. XIX–XX гасырларда туган телдәге (татар) әдәбият классиклары әсәрләре (шигырьләр, хикәяләр). Туган телдәге (татар) балалар әдәбияты классиклары әсәрләре (шигырьләр, хикәяләр, әкиятләр). Төрле халыклар (Россиянең күпмилләтле дәүләт булуын исәпкә алып) әдәбияты үрнәкләре (хикәяләр, әкиятләр). Балалар өчен вакытлы матбугат басмалары (журналлар).

**Әдәби пропедевтика**. Төрле типтагы рифмалар, халык иҗаты һәм автор әдәбияты әсәрләренең жанр үзенчәлекләрен тану, әдәби әсәрләрдәге тел-сурәтләү чаралары (синонимнар, антонимнар, сынландыру, чагыштырулар, эпитетлар, метафоралар һ.б.) белән танышу һәм аларның кулланылу үзенчәлеген аңлау.

Укучыларның татар халык иҗатының кече жанрлары турындагы белемнәрен системалаштыру һәм «халык авыз иҗаты» төшенчәсен үзләштерү. Әдәби күзаллау алымнарын формалаштыру. Фольклор әсәрләре турында билгеле бер караш булдыру. Фольклор әсәрләренең жанр төрлелеген (хайваннар турында әкиятләр, тылсымлы һәм көнкүреш әкиятләре; кече фольклор формалары: табышмаклар, санамышлар, бишек җырлары, мәкальләр һ. б.) ачу.

Автор әдәбияты: хикәя, әдәби әкият жанры, шигырьләр. Шигырьнең үзенчәлекләре (ритм, рифма). «Тема» һәм «төп фикер» төшенчәләре. Төрле жанрдагы әсәрләрне практик тану («жанр» төшенчәсен үзләштермичә). Әсәрнең герое, хикәяләүче һәм автор турында күзаллау тудыру.

Текстның халык авыз иҗаты яки автор әсәре булуын билгеләү. Текстның жанр үзенчәлекләре (әкият, хикәя, шигырь, мәкаль, табышмак һ.б.). Әдәби һәм фәнни-популяр текстлар арасындагы аерманы, проза һәм шигырь текстларының аерымлыкларын күрсәтү. Әдәби әсәрдә автор позициясен табу (укытучы ярдәмендә), шулай ук геройның (лирик геройның) кичерешләрен аңлау.

**Укучыларның иҗади эшчәнлеге.** Әдәби әсәрне (яки аның аерым өлешләрен) рольләргә бүлеп уку. Шигырь һәм проза әсәрләрен сәнгатьле укый белү. Интонация, уку темпын аңлы рәвештә сайлый һәм текст үзенчәлекләре нигезендә кирәкле паузалар ясый алу. Дәреслектәге иллюстрацияләрне анализлый белү, аларны әдәби текстлар белән чагыштыру. Кече фольклор жанрларын практик үзләштерү (табышмаклар, санамышлар, эндәшләр), үз текстын иҗат итү һәм аны тәэсирле чаралар (мимикалар, ишарәләр, интонацияләр) ярдәмендә инсценировкалау. Телдән һәм язма рәвештә (аерым җөмләләр һәм зур булмаган сочинениеләр рәвешендә) үзеңнең шәхси күзәтүләрең һәм тәэсирләрең белән уртаклаша алу.

«Туган телдә (татар телендә) әдәби уку» предметын өйрәнү нәтиҗәләре башлангыч гомуми белем бирүнең Федераль дәүләт белем бирү стандартында формалаштырылган төп белем бирү программасын үзләштерү буенча «Туган тел һәм туган телдә әдәби уку» предмет өлкәсе нәтиҗәләренә карата куелган таләпләргә туры килә.

## ПЛАНЛАШТЫРЫЛГАН НӘТИҖӘЛӘР

### Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр

«Туган телдә (татар телендә) әдәби уку» предметын өйрәнү укучыларда тәрбия эшчәнлегенең төп юнәлешләре буенча тәкъдим ителгән түбәндәге шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр формалаштырачак:

***патриотик һәм гражданлык тәрбиясе:***

- үз Ватаныңа — Россиягә югары кыйммәт итеп карау, шул исәптән илнең тарихын һәм мәдәниятен чагылдырган сәнгать әсәрләрен өйрәнү аша да;

- үзеңнең этномәдәни тәңгәллегеңне һәм Россия гражданины булуыңны аңлау;
- үз илеңнең һәм туган ягыңның үткәне, бүгенгесе һәм киләчәге белән бәйләнеш тою, шул исәптән сәнгать әсәрләрен өйрәнү барышында фикер алышу аша да;
- үз халкыңа һәм башка халыкларга хөрмәт белән карау, шул исәптән әдәби әсәрләр һәм фольклор әсәрләре аша да шундый ук хөрмәт тәрбияләүгә ирешү;
- әдәби әсәрләр һәм фольклор әсәрләрендә урын алган кыйммәтләргә, әдәп-әхлак нормаларына таянып, һәм гомумән, җәмгыятьнең бер әгъзасы булган кеше, аның хокуклары һәм бурычлары, хөрмәткә лаек булуы һәм абруе, кешеләр арасындагы үзара мөнәсәбәтләр турында беренчел күзаллау туу;

***рухи-әхлакый тәрбия:***

- уку нәтиҗәсендә һәм шәхси тормыш тәҗрибәсенә таянып, һәр кешенең индивидуаль шәхес булуын тану;
- тел нормалары, сөйләм әдәбе чикләрендә кешенең хәленә керү, хөрмәт һәм шәфкатьлелек күрсәтү, үз халәтен һәм хисләрен белдерү; башка кешеләрнең тойгыларын аңлау һәм уртаклашу, теләктәшлек күрсәтү;
- яшьтәшләре белән хезмәттәшлек итү, конфликтлар булдырмау һәм бәхәсле хәлләрдән чыгу юлларын табу, шул исәптән әдәби әсәрләр үрнәкләренә таяну;

***зәвык тәрбияләү:***

- мәдәниятебезне хөрмәт итү һәм аның белән кызыксыну, сәнгать төрләренә, үзеңнең һәм башка халыкларның традицияләренә, иҗатына ихтирам белән карау;
- сәнгатьнең төрле юнәлешләрендә, шул исәптән сүз сәнгатендә үз-үзеңне күрсәтергә, танытырга омтылу;
- физик тәрбия, сәламәт яшәү культурасы һәм эмоциональ тотрыклылык формалашу;
- әйләнә-тирә мохиттә өстәмә мәгълүмат эзләгәндә (шул исәптән цифрлаштырылган информацион кырда да), үзеңә

һәм башкаларга мөнәсәбәттә сәламәт һәм имин яшәү кагыйдәләрен үтәү;
- үз фикереңне җиткерүнең кулай ысулларын сайлау, сөйләм этикеты нормаларын һәм аралашу кагыйдәләрен үтәү нигезендә физик һәм психик сәламәтлеккә зарар китермәү;

***хезмәт тәрбиясе:***
- кеше һәм җәмгыять тормышында хезмәтнең югары кыйммәт булуын (шул исәптән әдәби әсәрләрдән алынган мисаллар ярдәмендә дә) аңлау, хезмәт нәтиҗәсенә җаваплы караш һәм сакчыл мөнәсәбәт, эшчәнлекнең төрле төрләрендә катнашу күнекмәләре, әдәби әсәрләр турында фикер алышу барышында танышкан төрле һөнәрләр белән кызыксыну;

***экологик тәрбия:***
- текстлар белән эшләү барышында табигатькә сакчыл мөнәсәбәт формалаштыру;
- үзенә зарар китерә торган гамәлләрне кабул итмәү;

***фәнни танып белү кыйммәтләре:***
- дөньяның фәнгә нигезләнгән картинасы турында беренчел күзаллаулар барлыкка килү, шул исәптән кайбер әдәби төшенчәләрне үзләштерү барышында да;
- танып белү мәнфәгатьләре, танып белүдә активлык, инициативалылык, кызыксыну һәм мөстәкыйльлек, шул исәптән әдәби әсәрләрне укуга игътибарлы мөнәсәбәт, уку даирәсен киңәйтүдә активлык һәм мөстәкыйльлек.

**Метапредмет нәтиҗәләр**

«Туган телдә (татар телендә) әдәби уку» предметын өйрәнү нәтиҗәсендә, укучыларда түбәндәге танып белү универсаль уку гамәлләре формалашачак.

***Төп логик гамәлләр:***
- төрле текстларны чагыштыру өчен, нигезләр табу, текстларның охшашлыгын күрсәтү;
- аерым бер билге буенча объектларны (текстларны) берләштерү;

- мәкальләрне, әйтемнәрне, фразеологизмнарны классификацияләү өчен төп үзенчәлекне билгеләү;
- укытучы тәкъдим иткән күзәтү алгоритмы нигезендә текстларда закончалыклар һәм каршылыклар табу; текстны тикшергәндә кулланылган гамәлләрнең алгоритмын анализлау, әлеге гамәлләрне мөстәкыйль рәвештә аерып күрсәтү;
- тәкъдим ителгән алгоритм нигезендә өйрәнү һәм гамәли бурычны хәл итү өчен, мәгълүматның җитмәвен ачыклау, җитешмәгән өстәмә мәгълүматны эзләргә өйрәнү;
- текстны анализлаганда, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләре урнаштыру, нәтиҗәләр ясау.

***Төп тикшеренү гамәлләре:***

- укытучы ярдәмендә максатны формалаштыру, сөйләм ситуациясе нигезендә үз фикереңне җиткерүне планлаштыру;
- биремне үтәүнең берничә вариантын чагыштыру, тәкъдим ителгән критерийлар нигезендә аеруча туры килә торганын сайлау;
- бирелгән план нигезендә катлаулы булмаган кечкенә тикшеренү үткәрү, проект биремен үтәү;
- нәтиҗәләрне формалаштыру һәм аларны текстка ясалган мәгънәви анализ нәтиҗәләре белән дәлилләп ныгыту; тәкъдим ителгән текстны анализлау барышында укытучы ярдәмендә сораулар формалаштыру;
- вакыйгалар, хәлләрнең мөмкин булган үсешен һәм бердәй яки охшаш шартларда аның нәтиҗәләрен фаразлау.

***Мәгълүмат белән эш:***

- мәгълүмат алу, төгәллек кертү чыганагын сайлау: кирәкле сүзлек, белешмәлек һ.б;
- бирелгән эш тәртибеннән чыгып, тәкъдим ителгән чыганактан (сүзлекләрдән, белешмәлекләрдән) төгәл мәгълүматны табу;
- мөстәкыйль рәвештә яисә укытучы тәкъдим иткән тикшерү ысулы нигезендә ышанычлы һәм төгәл булмаган мәгълүматны (сүзлекләргә, белешмәлекләргә, дәреслеккә мөрәҗәгать итеп) танып белү;

- Интернетта мәгълүмат эзләгәндә, өлкәннәр (педагогик хезмәткәрләр, ата-аналар яки аларны алмаштыручы законлы вәкилләр) киңәшен тотып, мәгълүмати иминлек кагыйдәләрен үтәү;
- уку бурычы таләбеннән чыгып, текст, график, видео, аудиоязма хәлендәге мәгълүмат булдыру һәм анализлау;
- таблица, схема рәвешендә китерелгән мәгълүматны аңлау; текстлар белән эшләүнең нәтиҗәләрен күрсәтү өчен, схемалар, таблицалар төзү.

Башлангыч мәктәп курсын тәмамлаганда, укучыда коммуникатив универсаль уку гамәлләре формалаша.

***Аралашу:***

- таныш мохиттә аралашу максатларыннан һәм шартларыннан чыгып, әйтелгән фикерләрне кабул итү һәм үз фикерләрен формалаштыру, хис-кичерешләрне белдерү;
- әңгәмәдәшкә хөрмәт саклау, диалог һәм әңгәмә алып бару кагыйдәләрен үтәү;
- карашлар төрле булу мөмкинлеген тану;
- үз фикереңне дөрес һәм дәлилле итеп әйтү;
- сөйләмне куелган бурычка нигезләнеп төзү;
- сөйләм ситуациясе нигезендә телдән һәм язма текстлар (тасвирлама, фикер йөртү, хикәяләү) булдыру;
- парлап һәм төркемдә эшләү, кечкенә тикшеренү, проект биреме нәтиҗәләре турында кыскача чыгышлар әзерләү;
- чыгыш текстына күргәзмә материал (рәсемнәр, фоторәсемнәр, плакатлар) сайлау.

***Күмәк эшчәнлек:***

- типик шартларда күмәк бурычны үтәү өчен, укытучы тәкъдим иткән планга сыешырлык итеп, үзең өчен кыска һәм дәвамлы вакыт аралыгына максатлар, аңа ирешү алымнарын һәм вакытын билгеләү;
- уртак эшчәнлекнең максатын аңлау, аңа ирешү өчен, күмәк гамәлләр кылу: килешенеп вазифаларны бүлү, уртак эш барышы һәм нәтиҗәсе турында фикер алышу;

- җитәкчелек итү, йөкләмәләр башкару; буйсынырга, каршылыкларны мөстәкыйль рәвештә хәл итәргә әзерләү;
- үз өлешеңә тигән эшне башкаруда җаваплылык хисе булдыру;
- гомуми нәтиҗәдә үзең керткән өлешне бәяләү;
- тәкъдим ителгән үрнәкләргә таянып, күмәк проект биремнәрен үтәү.

Башлангыч мәктәп программасын тәмамлаганда, белем алучының түбәндәге **регулятив-универсаль уку гамәлләре** формалаша.

***Оештыру:***

- нәтиҗәгә ирешү өчен, уку бурычын хәл итү эзлеклелеген планлаштыру;
- сайлап алынган гамәлләрнең эзлеклелеген булдыру.

***Үз-үзеңне тикшерү:***

- уку эшчәнлегенең уңышы һәм уңышсызлыгы сәбәпләрен билгеләү;
- сөйләм хаталарын һәм текстларны анализлауга бәйле хаталарны булдырмау өчен, үзеңнең уку эшчәнлегеңә төзәтмәләр кертү;
- эшчәнлек нәтиҗәсен текстларны анализлауга куелган уку бурычы белән чагыштыру;
- текстлар белән эшләгәндә җибәрелгән хатаны табу;
- үз эшчәнлеге һәм сыйныфташлары эшчәнлеге нәтиҗәләрен чагыштыру, аларны тәкъдим ителгән критерийлар нигезендә объектив бәяләү.

**Предмет нәтиҗәләр**

«Туган телдә (татар телендә) әдәби уку» предметын дүрт ел дәвамында өйрәнү түбәндәге нәтиҗәләрне тәэмин итәргә тиеш:

- татар әдәбиятын дөньякүләм һәм милли мәдәният күренеше, тормышны танып белүнең махсус ысулы, халкыбызның милли-мәдәни байлыгы, әхлакый кыйммәтләрне һәм традицияләрне саклау һәм тапшыру чарасы буларак аңлау;
- татар әдәбияты әсәрләрен өйрәнү нигезендә татар теленең коммуникатив-эстетик мөмкинлекләрен аңлау;

- туган телдәге әдәбиятны укуның шәхси үсеш, үзеңне, дөньяны, милли тарихны һәм мәдәниятне танып белү; мәдәни тәңгәллегеңне тану; татар әдәбиятын системалы укуга ихтыяҗ булдыру өчен, аның мөһимлегенә төшенү;
- укылган әсәрдәге каһарманнар гамәлләренең әхлакый нормалар белән тәңгәллеген ачыклау, әлеге гамәлләрне әхлакый бәяләүне нигезләү;
- метафораларның, сынландыруларның, эпитетларның милли үзенчәлеген аңлау;
- уку күнекмәләрен камилләштерү (кычкырып һәм эчтән уку, интерпретациянең элементар алымнарын белү, әдәби, фәнни-популяр текстларны анализлау һәм үзгәртеп кору);
- татар әдәбияты әсәрләрен уку тәҗрибәсен мөстәкыйль куллану (тыңланган / укылган текст буенча фикер алышуда катнашу, текстка сылтамалар белән үз фикереңне исбатлау һәм раслау; текст үзенчәлеген саклап, тыңлаган яки укыган текстның эчтәлеген кыскача яки тулысынча сөйләү; укылган әсәрләр нигезендә коммуникатив бурычны (төрле адресат өчен) исәпкә алып, телдән хикәя төзү, шигъри әсәрләрне яттан уку);
- кызыксындырган әдәбиятны мөстәкыйль сайлау һәм кызыксыну чикләрен киңәйтә бару;
- өстәмә мәгълүмат алу өчен, белешмә чыганаклардан файдалану.

**Уку елы тәмамланганда 4 нче сыйныф укучысы:**

*База өлешендә:*

- орфоэпик нормаларны саклап, интонацияне дөрес куеп, йөгерек итеп эчтән укырга;
- өйрәнелгән әдәби әсәрләрнең эчтәлеген белергә, аларның авторларын һәм исемнәрен күрсәтергә;
- текстны мәгънәви кисәкләргә бүләргә, план төзергә һәм шул план буенча аның эчтәлеген сөйләргә;
- мөстәкыйль рәвештә әсәр геройларын характерларга, геройларның гамәлләре, уйлары, хисләре арасында бәй-

лэнеш урнаштырырга; укылган әсәр геройлары турында үз фикерен белдерергә; билгеле бер әсәрдә һәм берничә әсәрдә авторның геройга мөнәсәбәтен билгели алырга;

- төрле авторларның 4–5 шигырен яттан белергә;
- тексттан тел-сурәтләү чараларын (чагыштыруларны) мөстәкыйль таба алырга, аларның әсәрдәге ролен аңларга;
- шәхси тәҗрибәгә нигезләнеп, иллюстрацияләр буенча, әдәби әсәргә нигезләнеп, үз текстын булдырырга;
- төрле чыганакларны һәм мәгълүмат эшкәртү ысулларын кулланып, проект биремнәрен башкарырга өйрәнә.

*Предметны тирәнтен өйрәнү өлешендә*:

- орфоэпик нормаларны саклап, интонацияне дөрес куеп, йөгерек итеп эчтән укырга;
- өйрәнелгән әдәби әсәрләрнең эчтәлеген белергә, аларның авторларын һәм исемнәрен атарга;
- укылган текст буенча әңгәмәдә катнашырга, әдәби әсәр яки персонаж турында үз фикерен дәлилләргә, моның өчен әсәрнең аерым өлешләрен яки аерым өзекләрен (юлларын, гыйбарәләрен) файдаланырга;
- текстны мәгънәви өлешләргә бүләргә, аның эчтәлеген җентекләп, сайлап алып, кыскача сөйләргә, текст буенча план төзергә, план нигезендә аның эчтәлеген сөйләргә;
- мөстәкыйль рәвештә әсәр геройларын характерларга, геройларның гамәлләре, уйлары, хисләре арасында бәйләнеш урнаштырырга; укылган әсәр геройлары турында үз фикерен белдерергә; билгеле бер әсәрдә һәм берничә әсәрдә авторның геройга мөнәсәбәтен билгели алырга;
- төрле авторның 5–6 шигырен яттан белергә;
- тексттан тел-сурәтләү чараларын (метафораларны) мөстәкыйль таба алырга, аларның әсәрдәге ролен билгеләргә;
- шәхси тәҗрибәгә нигезләнеп, иллюстрацияләр буенча, әдәби әсәргә таянып, үз текстын булдырырга;
- төрле чыганакларны һәм мәгълүмат эшкәртү ысулларын кулланып, проект биремнәрен башкарырга өйрәнә.

## ТЕМАТИК ПЛАНЛАШТЫРУ

| Тема | Эчтәлек | Укучылар эшчәнлегенең төрләре |
| --- | --- | --- |
| Матурлык минем белән (6 сәгать) | Тышкы һәм эчке дөнья матурлыгын ачуга юнәлтелгән әсәрләр:<br>**Р. Вәлиев.** «Яшә, көмеш кыңгырау»;<br>**Ф. Садриев.** «Могҗизалы дөнья»;<br>**В. Хәйруллина.** «Хозурлык һәм горурлык»;<br>**Р. Миңнуллин.** «Атказанган сандугач»;<br>**Ш. Галиев.** «Җирдә миңа ни кирәк?» (*яттан өйрәнү өчен*);<br>**Г. Мөхамматшин.** «Хыял».<br>*Сыйныфтан тыш уку:*<br>**Ф. Садриев.** «Алдау». | Эчтән уку.<br>Әдәби текст белән эш: мөстәкыйль рәвештә укылган әсәрнең темасын һәм төп фикерен билгеләү, әсәргә карата куелган сорауларны аңлау, әдәби герой турында үз фикерен дәлилләү, бу фикерне әсәрдән өзекләр белән раслау, текстны мәгънәви өлешләргә бүлү, план төзү һәм аны текст эчтәлеген сөйләгәндә куллану.<br>Декламацияләү: шигырьне сәнгатьле итеп яттан сөйләү.<br>Тикшерү эше: тест биремнәрен үтәү.<br>Сыйныфтан тыш уку: уку өчен тәкъдим ителгән исемлектән китап сайлап алу. |

| | | |
|---|---|---|
| Татар халык иҗаты. Мәзәкләр (2 сәгать) | Татар халык иҗаты. Халык иҗатының бер төре буларак мәзәкләр. Халык иҗатында халык психологиясе, аның идеаллары гәүдәләнеше. | Уку диалогы: халык иҗаты текстлары эчтәлегенә караган сорауларга җавап бирү, халык иҗаты әсәрләренең аермасын күрә белү.<br>Фольклор тексты белән эш: текстның төп фикерен билгеләү, әсәр геройлары турында фикер әйтү, бәя бирү.<br>Төрле чыганаклар белән мөстәкыйль эшләү.<br>Әдәби әсәрне интерпретацияләү: рольләргә бүлеп уку.<br>Иҗади эш: үрнәк нигезендә мәзәкләр иҗат итү.<br>Бирелгән темага проект эше эшләү. |
| Дуслык (7 сәгать) | Дуслык, үзара ярдәмләшү һәм бердәмлек турындагы әсәрләр:<br>**Б. Рәхмәт.** «Минем дусларым»;<br>**Д. Аппакова.** «Шыгырдавыклы башмаклар»;<br>**Р. Мингалим.** «Дусларың гына булсын» (*яттан өйрәнү өчен*); | Кычкырып уку: текстны сәнгатьле итеп уку.<br>Әдәби әсәрне интерпретацияләү: рольләргә бүлеп уку.<br>Уку диалогы: әсәр эчтәлегенә караган сорауларга җавап бирү, текстка карата сораулар (шулай ук проблемалы сораулар да) төзү.<br>Әдәби текст белән эш: укылган әсәрнең |

| | | |
|---|---|---|
| | **Х. Халиков.** «Яңа дус таптым»;<br>**Н. Сладков.** «Дуслар-ахирәтләр».<br>*Сыйныфтан тыш уку:*<br>**Д. Аппакова**. «Йолдызкай»;<br>**Н. Фәттах.** «Велосипедлы Мөнир»;<br>**М. Галләмова.** «Чын дус»; | төп фикерен билгеләү, әсәр геройларын характерлап бирү, аларның эш-гамәлләрен бәяләү, вакыйгалар эзлеклелеген күрсәтү.<br>Мөстәкыйль рәвештә үз сүзләре белән план төзү.<br>План нигезендә текстның (текстның бер өлешенең) эчтәлеген сөйләү.<br>Иҗади эш: фикерләүгә корылган текст булдыру, сочинение язу. |
| Табигать китабы (8 сәгать) | Туган ил, туган җирнең матурлыгы, табигать алдында кешенең җаваплылыгы турындагы әсәрләр:<br>**Р. Хафизова.** «Күңел күзе»;<br>**З. Туфайлова.** «Без утырткан урман»;<br>**Ж. Тәрҗеманов.** «Тукран малае Шуктуган»;<br>**З. Әхмәров.** «Агачлар да авырый»;<br>**Ә. Баян.** «Яхшылык кире кайта»; | Кычкырып уку: текстны сәнгатьле итеп уку.<br>Уку диалогы: текстның исеме, рәсемнәр һәм ачкыч сүзләр ярдәмендә текстның эчтәлеген фаразлау.<br>Әдәби текст белән эш: әсәр геройларына, аларның эш-гамәлләренә бәя бирү, геройның хис-кичерешләрен белдерә торган тел-сурәтләү чараларын күрсәтү.<br>План нигезендә текстның эчтәлеген сөйләү.<br>Иҗади эш: хикәяләү характерындагы текстка тасвирлама һәм фикер йөртү |

| | | |
|---|---|---|
| | **Ш. Галиев.** «Курыкма, тимим» (*яттан өйрәнү өчен*);<br>**Ф. Яруллин.** «Серле көндәлек».<br>*Сыйныфтан тыш уку:*<br>**А. Алиш.** «Нечкәбил»;<br>**Р. Миңнуллин.** «Җәяү йөрүче машина турында кечкенәкият». | юнәлешендәге элементлар өстәү, хикәя сюжетының алда мөмкин булган үстерелешен (вакыйгалар хәрәкәтен) фаразлау.<br>Декламацияләү: шигырьне сәнгатьле итеп яттан сөйләү.<br>Тикшерү эше: тест биремнәрен үтәү.<br>Сыйныфтан тыш уку: уку өчен тәкъдим ителгән исемлектән китап сайлап алу. |
| Күңелле бәйрәмнәр (6 сәгать) | Халкыбызның календарь бәйрәмнәре, гореф-гадәтләре һәм йолалары турындагы әсәрләр:<br>**С. Сөләйманова.** «Әниләр бәйрәме» (*яттан өйрәнү өчен*);<br>**Р. Хафизова.** «Нәүрүз килә»;<br>**Р. Зәйдулла.** «Сабантуй аланында»;<br>**Э. Шәрифуллина.** «Сабантуй»;<br>**Р. Миңнуллин.** «Әйлән-бәйлән»;<br>**Н. Гайсин.** «Бүген бәйрәм».<br>**Җ. Дәрзаман.** «Солдат булдым». | Текстны сәнгатьле итеп кычкырып уку.<br>Уку диалогы: әсәр эчтәлегенә караган сорауларга җавап бирү.<br>Әдәби текст белән эш: мөстәкыйль рәвештә әсәрнең төп фикерен билгеләү, әсәр геройларына, аларның эшгамәлләренә бәя бирү, геройның хискичерешләрен белдерә торган телсурәтләү чараларын күрсәтү, әдәби әсәрдән сәнгатьлелек чараларын табу.<br>План нигезендә текстны сөйләп бирү.<br>Телдән диалог һәм монолог рәвешендә фикерләр әйтү. |

| | | |
|---|---|---|
| | *Сыйныфтан тыш уку:*<br>**Р. Мөхәммәдиев.** «Яңа елга кучтәнәч»;<br>**Г. Гыйльманов**. «Бүләк». | Декламацияләү: шигырьне сәнгатьле итеп яттан сөйләү.<br>Проект эше эшләү.<br>Сыйныфтан тыш уку: уку өчен тәкъдим ителгән исемлектән китап сайлап алу. |
| Җиңү бәйрәме (5 сәгать) | Әсәрләрдә Җиңү бәйрәме темасы чагылышы. Сугышта һәлак булганнарны искә алу, ветераннарны хөрмәтләү, фронтовикларның истәлекләре;<br>**Р. Миңнуллин.** «Май килә»;<br>**Р. Корбан.** «Җиңү бәйрәме» (*яттан өйрәнү өчен*);<br>**М. Маликова.** «Һәйкәл янында»;<br>**В. Хәйруллина.** «Билгесез солдат»;<br>**Р. Харис.** «Сугыш турында сөйләшә картлар»;<br>**Ф. Садриев.** «Бабай сугышта булган».<br>*Сыйныфтан тыш уку:*<br>**Ф. Хөсни.** «Малай һәм солдат». | Текстны сәнгатьле итеп кычкырып уку.<br>Уку диалогы: әсәр эчтәлегенә караган сорауларга җавап бирү.<br>Әдәби текст белән эш: мөстәкыйль рәвештә әсәрнең төп фикерен билгеләү, әсәр геройларына, аларның эш-гамәлләренә бәя бирү, геройның хис-кичерешләрен белдерә торган тел-сурәтләү чараларын күрсәтү, сәнгатьлелек чараларының әдәби әсәрдәге вазифасын һәм әһәмиятен аңлату.<br>Укылган әсәрнең бер кисәгенә, эпизодына сүз белән сурәт тудыру.<br>Балалар өчен булган вакытлы матбугат – бер-ике журнал рубрикалары белән танышу.<br>Тикшерү эше: тест биремнәрен үтәү.<br>Сыйныфтан тыш уку: уку өчен тәкъдим ителгән исемлектән китап сайлап алу |

## ДӘРЕСЛЕК БЕЛӘН ЭШЛӘҮ ТӘРТИБЕ

Дәреслекнең һәр темасы дәрестә өйрәнелә торган әсәр белән бәйләп бирелә. Алдагы сыйныфлар өчен эшләнгән дәреслекләрдәге кебек үк теманы өйрәнүнең башыннан ахырына кадәр укучылар белән бергә белемнәрне дәреслек персонаж-геройлары – Алмаз, Гөлназ, Нур, Дәреслек тә үзләштерә. 4 нче сыйныф дәреслегендә аларга Фоат Садриевның «Тургай» исемле повестеннан Тургай кушаматлы Ислам исемле малай кушыла.

Бу персонажлар укучылар белән өйрәнелә торган темага һәм куелган уку мәсьәләсенә бәйле әңгәмә алып баралар. Мондый әңгәмәләр һәм төрле коммуникатив юнәлешле биремнәр укучыларның телдән һәм язма сөйләмнәрен үстерүгә хезмәт итеп кенә калмый, ә балаларның күңелләрен үстереп, әдәби әсәрне өйрәнүгә мотивлаштыруга да хезмәт итә.

Дәреслек ике төрле мәктәпне (татар һәм рус), ягъни ике дәрәҗәдә укуны (предметның база өлешен өйрәнүчеләр һәм тирәнтен өйрәнүчеләрне) күздә тотып төзелгән. 4 нче сыйныф дәреслегендә дә төрле дәрәҗәдә өйрәнелә торган материаллар аерып бирелә. Предметны тирәнтен өйрәнүчеләр өчен алар өстәмә рәвештә дәреслекнең чите буйлап төс һәм график сурәт (яшел пунктирлар) ярдәмендә билгеләнә. Ике дәрәҗәгә аерып бирү әсәр ахырыннан соң бирелгән сорау-биремнәрдә дә чагылыш таба. Укытучы өчен методик әсбапта предметны тирәнтен өйрәнү буенча киңәшләр, аерым темалар зәңгәр төс белән билгеләнә.

Дәреслектәге биремнәр, аеруча база өлешендәгеләре, теманы өйрәнүдә артык кыенлык тудырмаска тиеш. Тирәнтен өйрәнүчеләр өчен булган өстәмә материаллар, сорау-биремнәр укучыларның иҗади мөмкинлекләрен, билгеле бер әдәби-теоретик төшенчәләрне аңлауны күздә тотып төзелде.

Тексттан соң бирелгән сүзлекчәдә таныш булмаган сүз, аның татар телендәге синонимы (синоним булмаган очракта – урыны буш калдырылган) һәм рус теленә тәрҗемәсе бирелә.

4 нче сыйныф дәреслегендә әдәби-теоретик төшенчәләрдән рус телендә белем бирүче мәктәп программасын үзләштерүчеләргә *мәзәк, чагыштыру* тәкъдим ителә, татар мәктәпләрендә укучылар (предметны тирәнтен өйрәнүчеләр) *мәзәк, метафораны* өйрәнәләр.

Сабантуй бүләге рәвешендә тәкъдим ителгән мәкаль-әйтемнәрне белемнәрне ныгыту яки дәрескә йомгак ясау этабында уңышлы файдаланып була. Дәреслеккә кайбер дәрестән тыш уку өчен әсәрләр дә кертелгән.

Дәреслекнең электрон вариантында, төп материал белән беррәттән, һәр дәрестә куллану өчен өстәмә заманча материаллар урын алды: рәсемнәр, интерактив форматтагы эш төрләре, биремнәр һ.б. Текст белән эшләгәндә электрон дәреслектәге аудиоязмаларны тыңлатып була.

Дәреслектәге уку материалы өлешчә видеодәресләр форматында да тәкъдим ителә. 4 нче сыйныф өчен Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы сайтында урнаштырылган видеороликларның эчтәлеге Федераль дәүләт белем бирү стандартлары таләпләренә туры килә һәм алар Үрнәк эш программалары нигезендә эшләнгән. Видеодәресләрнең төп максаты – укучыларны яңа материал белән таныштыру, аны презентация яки анимация чаралары ярдәмендә аңлату. Бу видеоязмалардан дәресләрдә дә, дистанцион укытуда укучының уку материалын мөстәкыйль үзләштерүе барышында да файдаланырга мөмкин булачак. Шулай ук укучылар белән дәрестән тыш эшләгәндә дә аларны уңышлы кулланып була. Иң мөһиме – алар һәрвакыт укучыларның белем алуга ихтыяҗларын канәгатьләндерү һәм үстерү эшенә хезмәт итәргә тиеш.

# ДӘРЕС ЭШКӘРТМӘЛӘРЕНЕҢ ҮРНӘКЛӘРЕ

Методик ярдәмлектә бирелгән дәрес үрнәкләре укытучыга бары юнәлеш бирү һәм бу дәрестә игътибардан читтә калмаска тиешле төп моментларны искәртүне генә максат итә. Методик әсбапта тәкъдим ителгән дәрес үрнәкләрендәгечә генә эш итеп булмый, чөнки сыйныфтагы укучыларның гомум һәм шәхси мөмкинлекләре исәпкә алынырга тиеш. Әсәрне уку, сүзлек белән эшләү, сорауларга җавап бирү, әңгәмәнең ни рәвешле үткәрелүе укытучы ихтыярында. Өстәмә сорау-биремнәр төзегәндә, әңгәмәне үзе сайлаган темага оештырганда, ул үзе теләгәнчә эшли ала. Шуңа күрә дәрес үрнәкләрендә бу өлешкә киң тукталмадык.

**Тема**: Көмеш кыңгырау мәктәпкә чакыра

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* – җәйге ялны файдалы үткәрү зарурлыгын аңлау, яңа уку елына әзер булу; дөньяның матурлыгын күрә белү.

*Метапредмет нәтиҗәләр* – уку мәсьәләсен куя белү, чишү юлларын билгеләү, иптәшләренең җавапларын бәяләү; сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләре урнаштыру; әңгәмәдә катнашу, үз фикерен әйтә белү.

*Предмет нәтиҗәләр* – Разил Вәлиевнең «Яшә, көмеш кыңгырау» шигыренең эчтәлеген белү, аның буенча сорауларга җавап бирә алу.

**Материал:** Электрон дәреслек: Әдәби уку. 4 нче сыйныф. Ике кисәктә. Беренче кисәк: башлангыч гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен) / Г.Н. Мөхәрләмова, Д.М. Абдуллина. – Казан, 2023 / http://litcorpus.antat.ru/ADABI_UKU/4snf/part1/

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, иллюстрацияләр, видеоролик.

## Дәрес барышы

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

Исәнләшү.

Уңай психологик халәт тудыру.

**II. Актуальләштерү.**

Дәрес кереш сүздән башланып итә. Дәреслектә авторларның укучыларга мөрәҗәгате бирелә. Шулар белән таныштырганнан соң, «Көмеш кыңгырау мәктәпкә чакыра» темасына кереп китәбез. Биредә дәреслек перонажларының әңгәмәсен куллана алабыз. Шулай ук бу очракта видеодәрес материалыннан файдаланырга мөмкин.

Темага кызыксыну уяту максатыннан, мәктәпкә кирәкле әсбапларны шакмакларда билгеләп, уен үткәреп була. Таблицада бирелгән сүзләрдән тыш мәктәпкә тагын нәрсәләр кирәк булуын ачыклыйбыз.

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

Дәреснең максатлары билгеләнә.

**IV. Уку мәсьәләсен адымлап чишү.**

Дәрестә Разил Вәлиевнең «Яшә, көмеш кыңгырау!» шигырен өйрәнү каралган. Видеодәрес материалыннан файдаланып, әсәр текстын диктор укуында тыңлатырга мөмкин. Алга таба шигырьне берничә яхшы укучыдан укытып була.

Тирәнтен өйрәнүчеләрдән белем илен ничек күзаллаулары турында сорашабыз. *Ил гизсәк тә, йөрәкләрдә басылмады ярсулар* дигән юлларны ничек аңлауларын ачыклаганда, үз тормышлары белән бәйләп сөйләтергә тырышабыз.

Әлеге дәрестә предметны тирәнтен өйрәнүчеләрнең программага кергән тагын бер әсәр белән танышуы күздә тотыла. Фоат Садриевның «Тургай» исемле повестеннан алынган «Могҗизалы дөнья» дип исемләнгән өзекне өйрәнү текстны уку, аңлашылмаган сүзләрне ачыклау, сорауларга җавап бирү рәвешендә бара.

**V. Белемнәрне беренчел ныгыту.**

Шигырь эчтәлеге буенча сорауларга җавап бирү укучыларның җәйге ялларын ничек үткәрүләре турында сөйләшүгә алып чыга.

Тема ахырында бирелгән мәкальдән һәр әйбернең, вакытның, шөгыльнең үз урыны булу, тиешле вакытта укырга, эшләргә дә кирәклекне аңлап була.

Бу өлештә дәреслек персонажларының Фоат Садриев повесте герое Тургай-Исламны балаларның үзләре белән сәяхәткә чакырулары турында әңгәмәсен кулланабыз. Шул рәвешле, ул 4 нче сыйныф дәреслеге персонажына әйләнә. Сторителлинг вакытында ул әледән-әле укучыларга дәреслек битләрендә очрап торачак.

**VI. Өй эше бирү.**

Шигырьне сәнгатьле итеп укырга.

**VII. Рефлексия.**

Дәрестә өйрәнелгәннәргә нәтиҗә ясала.

Бәяләү, үзбәя бирелә.

**Тема**: Зәңгәр күк, алтын кояш

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* – хозурлану, горурлану хисләренә төшенү.

*Метапредмет нәтиҗәләр* – фаразлау, уку мәсьәләсен куя белү, иптәшләренең җавапларын бәяләү, үзбәя; мәгълүмат алу, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләре урнаштыру; диалог һәм әңгәмә алып бару кагыйдәләрен үтәү, үз фикерен дәлилләп әйтә белү, сөйләм ситуациясе нигезендә язма һәм телдән текстлар булдыру.

*Предмет нәтиҗәләр* – Вәсимә Хәйруллинаның «Хозурлык һәм горурлык» шигыренең эчтәлеген белү, шигырьнең төп фикерен аерып чыгару.

**Материал:** Электрон дәреслек: Әдәби уку. 4 нче сыйныф. Ике кисәктә. Беренче кисәк: башлангыч гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен) / Г.Н. Мөхәрләмова, Д.М. Абдуллина. – Казан, 2023 / http://litcorpus.antat.ru/ADABI_UKU/4snf/part1/

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, иллюстрацияләр, видеоролик.

**Дәрес барышы**

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

Исәнләшү.

Уңай психологик халәт тудыру.

**II. Актуальләштерү.**

Өй эшен тикшерү.

Темага алып кереп китү өчен, Гөлназның дәреслектәге сүзләреннән (15 бит) файдалану уңайлы. Биредә видеодәрес материалыннан да файдаланырга мөмкин.

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

Дәреснең темасы, максаты билгеләнә.

**IV. Уку мәсьәләсен адымлап чишү.**

«Зәңгәр күк, алтын кояш» темасын ачуга Вәсимә Хәйруллинаның программада каралган «Хозурлык һәм горурлык» шигыре булышлык итә. Сорауларга җавап биргәндә, шигырь текстын икегә бүлеп, шул өлешләрнең бәйләнешен ачыкларга кирәк булачак. Укучылар бу бәйләнешне туган илнең матур, ямьле якларының шигырь героенда соклану, хозурлану һәм горурлык хисләре уятуында күрергә тиеш булалар.

Предметны тирәнтен өйрәнүчеләргә катлаулырак сорау-биремнәр тәкъдим ителә. Әйтик, *янәшәмдә күләгәм* дигән сүзләрдән бала шигырьдә сүз кояшлы, якты көн турында баруын билгеләргә тиеш була. *Матурлык, хозурлык кая чакыра ала?* дигән сорауга, укучы *хыялларга, сәяхәтләргә, зур эшләргә һ.б. чакыра* дип җавап бирә ала.

Шулай ук база өлешен өйрәнүчеләргә (рус мәктәпләрендә укучы татар балаларына) программада *чагыштыру* турында төшенчә бирү каралган. Предметны тирәнтен өйрәнүчеләр чагыштыруны (сурәтләү чарасы буларак) 3 нче сыйныфта өйрәнгәннәр иде, хәзер исә билгеләмәне искә төшереп ныгыту файдалы була ала. *Бакчадагы алмагачның чәчәкләрен шагыйрь нәрсә белән чагыштыра?* дигән сорау (сораулыкта бирелгән) өлешчә чагыштыруның асылын аңлауга юнәлеш бирә. Дәреслектә чагыштыруга билгеләмә бирелгән. Укучылар үз мисалларын китерсә, бик яхшы була.

**V. Белемнәрне беренчел ныгыту.**

Дәреслектәге Мансур турындагы хикәя укучыларны төшенкелеккә бирелмәскә чакыра, үз уңышсызлыкларында башкаларның

гаебе булмавына төшенергә мөмкинлек бирә. Укучылар, Мансурның эш-гамәлләрен бәяләп, шул фикергә килә алачаклар. Мансурга биргән киңәшләрен дә тыңларга кирәк.

Бу хикәяне уку база өлешен генә өйрәнүчеләр өчен дә файдалы булачак.

**VI. Өй эше бирү.**

«Мин бу дөньяда нәрсәләр белән хозурланам» дигән темага зур булмаган хикәя төзеп килергә.

**VII. Рефлексия.**

Дәрестә өйрәнелгәннәргә нәтиҗә ясала.

Бәяләү, үзбәя бирелә.

**Тема**: Кошлар да китеп барды

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* – күренекле шәхесләргә карата ихтирам хисенә ия булу.

*Метапредмет нәтиҗәләр* – уку мәсьәләсен куя белү, иптәшләренең җавапларын бәяләү, үзбәя; сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләре урнаштыру, укытучы тәкъдим иткән тикшерү ысулы нигезендә ышанычлы һәм төгәл булмаган мәгълүматны танып белү, тамга-символик чараларны куллану; әңгәмәдә катнашу, сөйләм ситуациясе нигезендә телдән һәм язма текстлар булдыру.

*Предмет нәтиҗәләр* – Роберт Миңнуллинның «Атказанган сандугач» шигыренең эчтәлеген белү, сорауларга җавап бирә алу.

**Материал:** Электрон дәреслек: Әдәби уку. 4 нче сыйныф. Ике кисәктә. Беренче кисәк: башлангыч гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен) / Г.Н. Мөхәрләмова, Д.М. Абдуллина. – Казан, 2023 / http://litcorpus.antat.ru/ADABI_UKU/4snf/part1/

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, иллюстрацияләр.

## Дәрес барышы

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

Исәнләшү.

Уңай эмоциональ халәт тудыру.

Гарифҗан Мөхәммәтшинның «Рәсем ясадым» шигырен уку.

**Рәсем ясадым**

Ямь-яшел буяп куйдым
Иркен яшел болынны,
Җирән белән – шул болында
Уйнап йөргән колынны.

Кызыл чәчәкләр ясадым
Болынга нур тулсын, дип,
Зәңгәрләрен дә өстәдем
Чәчәкләр мул булсын, дип.

Якты аяз күк йөзен мин
Буяп куйдым күк төскә,
Көлеп торган сары кояш
Ясап куйдым иң өскә.
Тургайсыз нинди болын,
Ялгыз уйнармы колын?

Соры карандаш белән
Ясап куйдым тургайлар.
Алар – күктә, колын – җирдә,
Узыш-узыш уйныйлар.
Ни җитми икән тагын,
Нишләтим төснең агын?

Бик тырышып карап чыктым
Тагын бер кат барчасын.
Җә, белдем, юк колынның
Маңгаенда кашкасы…
Бары да булды кебек,
Шатлыктан куйдым көлеп.

Шигырь буенча әңгәмә үткәрәбез. Тулы күзаллау булдыру өчен шигырьне уку барышында шул күренеш тасвирланган рәсемнәр күрсәтә алабыз.

**II. Актуальләштерү.**

Өй эшен тикшерү: алдагы дәрестә өйдә шигырьне сәнгатьле итеп укырга өйрәнергә кушылган була, берничә укучыдан укытабыз.

Дөньяның матурлыклары турында сөйләшүне дәвам итеп, укучылар белән аның гүзәллекләрен барлыйбыз.

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

Дәреснең темасын һәм максатын билгеләү өчен персонажларның 16 биттәге диалогы белән таныштырабыз. Шуңа нигезләнеп, укучылар дәрестә нәрсә турында сүз барачагын фаразлап әйтә алачаклар.

**IV. Уку мәсьәләсен адымлап чишү.**

Роберт Миңнулинның «Атказанган сандугач» исемле шигыре укыла, электрон дәреслектән аудиоязманы да тыңлатырга мөмкин. Шигырь буенча сорауларга җаваплар алганчы, сандугач турында мәгълүмат биреп, сөйләп китсәк яхшы була. Бу кошның сайравын ишеткән укучыларның тәэсирләрен сораштырып, әңгәмә үткәрергә мөмкин. Биредә шулай ук *атказанган* сүзенә аңлатма бирү сорала.

**V. Белемнәрне беренчел ныгыту.**

Дөньяны матурлауда кошларның әһәмияте турында сөйләшеп була.

Предметны тирәнтен өйрәнүчеләргә атказанган исеменең кемнәргә бирелүен, мондый исемне йөрткән кешеләрдән кемнәрне белүләрен сораштыра алабыз.

Дәреслекнең «Сабантуй бүләге» рубрикасында татар рәссамы, Россиянең һәм Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Лотфулла Фәттахов турында мәгълүмат бирелә. Укучыларны аның белән таныштырабыз, рәссамның портретын күрсәтәбез, иҗат иткән әсәрләренә күзәтү ясыйбыз һәм, сөйләм телен үстерү максаты белән, Лотфулла Фәттаховның дәреслектә бирелгән «Сабантуй» картинасы буенча эш үткәрәбез.

**VI. Өй эше бирү.**

Шигырьне сәнгатьле укырга өйрәнергә. Картина буенча төзегән хикәяне дәфтәргә язып килергә.

**VII. Рефлексия.**

Дәрестә өйрәнелгәннәргә нәтиҗә ясала.

Бәяләү, үзбәя бирелә.

**Тема**: Җирдә безгә ни кирәк?

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* – әти, әни, туган тел, туган ил төшенчәләрен аңлап, аларның әһәмиятенә төшенү.

*Метапредмет нәтиҗәләр* – уку мәсьәләсен куя белү, фаразлау, иптәшләренең җавапларын бәяләү, үзбәя; сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләре урнаштыру; диалог һәм әңгәмә алып бару кагыйдәләрен үтәү, үз өлешеңә тигән эшне башкаруда җаваплылык хисе булдыру, үз фикереңне дөрес һәм дәлилле итеп әйтү.

*Предмет нәтиҗәләр* – Шәүкәт Галиевнең «Җирдә миңа ни кирәк?» шигыренең эчтәлеген белү, төп фикерне аңлау.

**Материал:** Электрон дәреслек: Әдәби уку. 4 нче сыйныф. Ике кисәктә. Беренче кисәк: башлангыч гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен) / Г.Н. Мөхәрләмова, Д.М. Абдуллина. – Казан, 2023 / http://litcorpus.antat.ru/ADABI_UKU/4snf/part1/

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, иллюстрацияләр.

**Дәрес барышы**

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

Исәнләшү.

Уңай эмоциональ халәт тудыру.

Нәкый Исәнбәтнең «Иң матур сүз» шигырен укып китәбез.

**Иң матур сүз**

– Син яраткан иң матур сүз
Нинди сүз, әйт, бәбкәем?

– Иң назлы сүз, иң якын сүз,
Ул матур сүз – әнкәем!
– Бар тагын бер иң матур сүз:
Һәрвакыт син әйткәнең.
Анысы нәрсә?
– Ул матур сүз,
Ул якын сүз – әткәем!
– Үскәнем, йә инде син әйт!
– Иң матур сүз – Илкәем.
Анда мин, син – һәммәбез дә,
Анда әткәй-әнкәем.

*Нәкый Исәнбәт*

Шигырьдә язылганнар турында укучыларның фикерләрен сораштыру.

**II. Актуальләштерү.**

Өй эшен тикшерү: алдагы дәрестә өйдә шигырьне сәнгатьле итеп укырга өйрәнергә кушылган була, берничә укучыдан укытабыз.

Лотфулла Фәттахов картинасы буенча язылган иҗади эшләрне кычкырып укытабыз.

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

Дәреснең темасын һәм максатын билгеләү өчен персонажларның 34 биттәге әңгәмәсе белән танышабыз. Шуларга нигезләнеп, укучылар дәрестә нәрсә турында сүз барачагын фаразлап әйтә алачаклар.

**IV. Уку мәсьәләсен адымлап чишү.**

Шәүкәт Галиевнең «Җирдә миңа ни кирәк?» шигыре сәнгатьле итеп укыла. Аның буенча сорауларга җаваплар биргәндә, укучылардан тормыш белән бәйләп сөйләү сорала. Шулай ук *әллүкиле көй* төшенчәсен аңлатып китеп, «Әллүки көе» турында сөйләсәк, отышлы булыр. Аны тыңлау мөмкинлеге тудырылса, тагын да яхшырак.

**V. Белемнәрне беренчел ныгыту.**

Әти, әни, туган ил турында әңгәмә оештырабыз.

Туган якның матурлыгы турында сөйләшәбез. Сөйләшүгә алып керү максаты белән дәреслек персонажларының әңгәмәсен укырга тәкъдим итеп була.

Сөйләшкәннәргә нәтиҗә ясау өчен «Сабантуй бүләге» рубрикасында бирелгән мәкаль, Мансур турындагы хикәя белән эшлибез.

**VI. Өй эше бирү.**

Шигырьне ятларга.

**VII. Рефлексия.**

Дәрестә өйрәнелгәннәргә нәтиҗә ясала.

Бәяләү, үзбәя бирелә.

**Тема**: Хыял дингезендә

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* – хыяллана белүнең әһәмиятенә төшенү, кешеләргә теләктәшлек белдерү, авыр чакта ярдәм кулы суза белү зарурлыгын аңлау.

*Метапредмет нәтиҗәләр* – фаразлау, уку мәсьәләсен куя белү, иптәшләренең җавапларын бәяләү; мәгълүмат алу, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләре урнаштыру; әңгәмәдә катнашу, үз фикерен әйтә белү, сөйләм ситуациясе нигезендә язма текст булдыру.

*Предмет нәтиҗәләр* – Гарифҗан Мөхәммәтшинның «Хыял» шигыренең эчтәлеген белү, төп фикерне билгели алу.

**Материал:** Электрон дәреслек: Әдәби уку. 4 нче сыйныф. Ике кисәктә. Беренче кисәк: башлангыч гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен) / Г.Н. Мөхәрләмова, Д.М. Абдуллина. – Казан, 2023 / http://litcorpus.antat.ru/ADABI_UKU/4snf/part1/

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, иллюстрацияләр.

## Дәрес барышы

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

Исәнләшү, уңай эмоциональ халәт тудыру.

**II. Актуальләштерү.**

Өй эшен тикшерү.

Дәреслек персонажларының әңгәмәсе белән таныштырабыз. Алдагы сыйныфта Алмазның хыяллануыин искә төшерәбез. Кемнең хәтере яхшы? дигән уен уйнатып була. Алмазның нәрсә турында хыяллануын кем тизрәк искә төшерә, шул җиңүче була.

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

Укучылар дәрестә сүзнең хыяллану турында барачагын әйтәләр.

**IV. Уку мәсьәләсен адымлап чишү.**

Гарифҗан Мөхәммәтшинның «Хыял» шигыре – яшерен мәгънәне табуга корылган әсәр. Укучыларның игътибарын шигырьдәге *инеш, кораб* образларына юнәлтәбез. Аларның нинди мәгънә белдерүен ачыклатабыз. Бу вакытта тормыш белән бәйләп, укучыларга да кораб йөздергән вакытларны искә төшерү мөмкинлеге бирәбез. *Күңеле – океаннарда* дигән гыйбарәгә игътибарны юнәлтәбез.

Предметны тирәнтен өйрәнүчеләрне уйлануга этәреп, корабның инеш буенча йөзүе белән малайның уйлары арасындагы бәйләнешне таптырабыз.

**V. Белемнәрне беренчел ныгыту.**

Тургайның теләге изге. Тирәнтен өйрәнүче укучылар, аның фикерен укып, шул турыда беләләр.

Бу фикергә мисал итеп дәреслектә Гүзәл Әдһәмнең «Тылсымлы чәчәк» хикәясе бирелә. Хикәяне укый башлауга ук, күп кенә укучылар әсәрдә Валентин Катаевның «Цветик-семицветик» әкияте телгә алынуын әйтә алалар. «Тылсымлы чәчәк» хикәя-

се – шуның интерпретациясе дисәк тә, ялгыш булмас. Биредә шул рәвешле рус әдәбияты дәресе белән бәйләнеш урнаштырыла.

Хикәя хәзерге заманга бәйләп иҗат ителгән, шуңа күрә укучыларда зур кызыксыну уятырга тиеш. Иң мөһиме – әсәрнең төп фикеренә төшенү. Ул үзеңнен мәнфәгатьләреңне өстен куймыйча, башкаларга ярдәм итәргә, аларны шатландырырга ашык, дигән фикер буларак формалаша.

**VI. Өй эше бирү.**

Үзеңнең хыялларың турында зур булмаган инша язып килергә.

**VII. Рефлексия.**

Дәрестә өйрәнелгәннәргә нәтиҗә ясала.

Бәяләү, үзбәя бирелә.

**Тема**: Матурлык минем белән (кабатлау)

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* – һәрнәрсәдә матурлык күрә белү.

*Метапредмет нәтиҗәләр* – уку мәсьәләсен куя белү, иптәшләренең җавапларын бәяләү, үзбәя; алгоритм буенча эшләү, гомумиләштерү, нәтиҗә чыгару, проект биремен үтәү; диалог һәм әңгәмә алып бару кагыйдәләрен үтәү, үз фикерен дәлилләп әйтә белү, сөйләм ситуациясе нигезендә телдән текст булдыру.

*Предмет нәтиҗәләр* – белемнәрне гомумиләштереп системага сала алу.

**Материал:** Электрон дәреслек: Әдәби уку. 4 нче сыйныф. Ике кисәктә. Беренче кисәк: башлангыч гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен) / Г.Н. Мөхәрләмова, Д.М. Абдуллина. – Казан, 2023 / http://litcorpus.antat.ru/ADABI_UKU/4snf/part1/

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, иллюстрацияләр.

## Дәрес барышы

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

Исәнләшү.

Уңай психологик халәт тудыру.

**II. Актуальләштерү.**

Үткән дәрестә өйрәнелгәннәрне сораштыру.

Хөрмәтле Дәреслекнең дәреслектәге сүзләре белән таныштырабыз. Аларның мәгънәсен ачыклыйбыз.

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

Укытучы укучыларга дәрестә нәрсә эшләячәкләрен җиткерә.

**IV. Белемнәрне ныгыту.**

Дәрестә зур тема кысаларында өйрәнелгән әсәрләрне искә төшерү күздә тотыла. Дәреслектә сораулар бирелгән, аларга җавапларны укучылар укытучы белән бергәләп табалар. Укучы үзенең фикерен җиткергән вакытта дәлилләр, мисаллар китереп барса, яхшы була.

Шулай ук бу дәрестә укучыларның алдан әзерләп килергә кушылган проект эшләрен дә тәкъдим итеп була. Әлеге проектны укучылар күмәкләп (парларда, төркемнәрдә) эшләсәләр, тагын да яхшы була.

Ахырдан укучыларга дәреслектәге уен кызыклы булачак. Уен барышында укучыларга МАТУРЛЫК сүзеннән мөмкин кадәр күбрәк сүзләр уйлап табарга кушыла.

Шулай ук Гөлназ китапханәсеннән булган китаплар белән дә танышу күздә тотыла.

**V. Өйгә эш бирү.**

«Мин матурлыкны нәрсәдән күрәм?» дигән темага хикәя төзеп килергә.

**VI. Рефлексия.**

Дәрестә өйрәнелгәннәргә нәтиҗә ясала.

Бәяләү, үзбәя бирелә.

**Тема**: Мәзәк сөйлим, тыңлагыз

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* – тормышта күзәтүчәнлеккә өйрәнү, һәр әйберне, күренешне төрлечә күреп, төрле ягыннан бәяләргә мөмкин икәнен аңлау.

*Метапредмет нәтиҗәләр* – уку мәсьәләсен куя белү, иптәшләренең җавапларын бәяләү; алгоритм буенча эшләү, иҗади күзаллау, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләре урнаштыру; әңгәмәдә катнашу, үз фикерен әйтә белү, сөйләм ситуациясе нигезендә телдән текст булдыру.

*Предмет нәтиҗәләр* – халык авыз иҗаты буларак, мәзәк төшенчәсен үзләштерү, мәзәкләр буенча сорауларга җавап бирә белү.

**Материал:** Электрон дәреслек: Әдәби уку. 4 нче сыйныф. Ике кисәктә. Беренче кисәк: башлангыч гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен) / Г.Н. Мөхәрләмова, Д.М. Абдуллина. – Казан, 2023 / http://litcorpus.antat.ru/ADABI_UKU/4snf/part1/#p=0

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, иллюстрацияләр.

## Дәрес барышы

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

Укучылар белән исәнләшү, дәрескә әзерлекләрен сораштыру, дәрескә оештыру.

**II. Актуальләштерү.**

Укучыларның халык авыз иҗаты турындагы белемнәренә нигезләнеп, аңа хас үзенчәлекләрне, фольклор җанрларын искә төшерергә мөмкин.

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

Алдагы сөйләшүгә бәйләп, халык авыз иҗатының тагын бер кызыклы жанры – мәзәкләр, дип хәбәр итәргә мөмкин.

**IV. Уку мәсьәләсен адымлап чишү.**

Игътибарны дәреслек геройларына юнәлтсәк, аларның әңгәмәсе мәзәкләр белән танышу мөмкинлеге тудыра. Мәзәкләр белән танышканда, аларның бер кызыклы хәлне генә түгел, ә тапкырлыктан, төрле кешеләрнең бер үк әйбернең (күренешнең) төрле ягына игътибар итүеннән, аны төрлечә аңлавыннан килеп чыгуын күрергә өйрәтәбез. Мәсәлән, Гөлназ сөйләгән мәзәктә кызчыкның песи баласын бирәсе килми. Әмма ул аны бирергә теләмим, дип әйтми. Тапкырлык күрсәтеп хәл итә. Алмаз сөйләгән «Йөз балык» мәзәгендә ике якның (әңгәмәдәшләрнең) балыкның зурлыгын төрлечә күзаллаулары мәзәк тудыра. «Менә гаҗәп» дигән мәзәк тә шул алымны кулланудан туган. Укучыларга мәзәк кызыклы күңел ачу чарасы булса да, аның асылында халык иҗатына хас булган тапкырлык һәм тәрбия бирү, әхлаклылыка өйрәтү ятканын да искәртү кирәк.

Алга таба укучыларны мәзәк төшенчәсенә аңлатма белән таныштыру, һәм аны ничек аңлаулары белән кызыксыну сорала.

Тирәнтен өйрәнүчеләр алдагы дәрестә мәзәкләр иҗат итүдәге үзенчәлекләр белән тирәнтенрәк таныша һәм мәзәк иҗат итеп тә карый.

**V. Белемнәрне беренчел ныгыту.**

Дәреслектә (48 бит) Хөрмәтле Дәреслек тәкъдим иткән бирем укучыларга мөстәкыйль рәвештә мәзәкләр тудыру алымын кулланып карарга мөмкинлек бирә. Сорауларга (49 бит) җавап бирү теманы тулысынча ныгытырга ярдәм итә.

**VI. Өйгә эш бирү.**

Мәктәп темасы белән бәйле мәзәк сөйләргә әзерләнеп килергә.

**VII. Рефлексия.**

Дәрестә өйрәнелгәннәргә нәтиҗә ясала.

Бәяләү, үзбәя бирелә.

**Тема:** Мәзәкләр ничек туа?

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* – тапкырлыкка, юмор хисенә ия булу.

*Метапредмет нәтиҗәләр* – уку мәсьәләсен куя белү, иҗади күзаллау, тәкъдим ителгән алгоритмга таянып эш итә белү; күзәтә һәм нәтиҗә ясый алу; әңгәмәдә катнашу, үз фикерен әйтә белү.

*Предмет нәтиҗәләр* – халык авыз иҗатының бер жанры булган мәзәкләрнең үзенчәлеген аңлау.

**Материал:** Электрон дәреслек: Әдәби уку. 4 нче сыйныф. Ике кисәктә. Беренче кисәк: башлангыч гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен) / Г.Н. Мөхәрләмова, Д.М. Абдуллина. – Казан, 2023 / / http://litcorpus.antat.ru/ADABI_UKU/4snf/part1/

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, иллюстрацияләр.

## Дәрес барышы

**I. Оештыру-мотивлаштыру**

Исәнләшү.

Уңай психологик халәт тудыру.

**II. Актуальләштерү.**

Бу этапта укучыларның өйдә әзерләп килгән мәзәкләрен тыңларга мөмкин.

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

Уку мәсьәләсен куярга дәреслек геройларының әңгәмәсе ярдәм итә ала.

Шуның нигезендә алар бу дәрестә мәзәкләрнең ничек тууы турында сөйләшәчәкләрен билгелиләр.

**IV. Уку мәсьәләсен адымлап чишү.**

Нурның тәкъдиме белән мәзәкнең ничек барлыкка килүен аңларга омтылыш тудыру һәм аны дәреслек геройлары белән бергәләп тикшерү мәзәкнең асылын аңларга ярдәм итәчәк.

Мәзәкнең көтелмәгән тапкыр җаваптан һәм каршылыктан туганлыгы аңлашыла.

Алга таба дәреслек геройларының әңгәмәсе укучыларга мөстәкыйль рәвештә мәзәк тудырырга мөмкинлек бирә. Әмма бу очракта аларга әле Нур ярдәмгә килә.

Бу биремне үтәү укучыларга мәзәкнең төзелешен, үзенчәлеген аңларга булыша.

Дәреслектә Алмаз тарафыннан тәкъдим ителгән мәзәктән соң, укучыларның өйдә әзерләп килгән берничә мәзәген тыңларга була. (Актуальләштерү өлешендә бөтенесен дә тыңлап бетерү мөмкин түгел.)

Эшне дәреслектә бирелгән фразеологизмнар ярдәмендә мәзәкләр тудырып дәвам итәргә кирәк. Моның өчен аларның мәгънәсендәге каршылыкны төшендерү, туры мәгънәдә түгеллеген аңлату сорала. Мәсәлән, «йөзе качкан» гыйбарәсендә качу мәгънәсе юк. Шуны аңлау мәзәк тудырырга ярдәм итә. Мәсәлән:

*Айдар ялгыш гөлнең иң матур чәчәген сындырды. Шулвакыт бүлмәгә әнисе килеп керде. Улының куркудан агарынган йөзен күреп:*

*– Улым, йөзең качкан, әллә берәр нәрсә булдымы?– дип сорады.*

*Айдарның тиз генә әнисе каршысыннан китәсе килде. Ул:*

*– Юк, әни, берни дә булмады? Шулай да йөземне куып тотыйм әле, ерак качканчы, – дип бүлмәдән чыгып йөгерде.*

Укучылар үзләре мөстәкыйль рәвештә мәзәк тудыруга ирешә алсалар, мәзәкләрнең үзенчәлеген тирәнрәк аңлый алачаклар.

**V. Белемнәрне беренчел ныгыту.**

Мәзәк турында алган белемнәрне искә төшерү укучыларга мәзәкнең үзенчәлеген аңлауларын тикшерергә ярдәм итә алырдай сораулар бирелә.

Мәзәкнең көлке генә түгел, ә тәрбия чарасы да булуы, яхшыны яманнан аерырга өйрәтүе, зирәклек, тапкырлык нәтиҗәсендә тууы дәлилләнә.

**VI. Өй эше бирү.**

Аерым бер альбом битенә балалар тормышы белән бәйле бер мәзәк язарга, аның читләренә матурлап бизәк төшерергә. Эш

уңышлы булсын өчен, үрнәкне күрсәтеп бирергә кирәк. (Алдагы дәрестә китапчык итеп тегеп куела, сыйныф китапханәсендә укучыларның үзләре ясаган китапчыклары арасында урын ала. Бәлки, хезмәт дәресендә китапчыкның тышын бизәү, тегүне бергәләп эшләп бетерергә мөмкин булыр.)

**VII. Рефлексия.**

Дәрестә өйрәнелгәннәргә нәтиҗә ясала.

Бәяләү, үзбәя бирелә.

**Тема**: Минем дусларым

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* – дусларың күп булуның яхшы икәнлеген аңлау.

*Метапредмет нәтиҗәләр* – фаразлау, уку мәсьәләсен куя белү, иптәшләренең җавапларын бәяләү; сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләре урнаштыру; әңгәмәдә катнашу, диалог һәм әңгәмә алып бару кагыйдәләрен үтәү, монологик сөйләм төзү, үз фикерен әйтә белү.

*Предмет нәтиҗәләр* – Бари Рәхмәтнең «Минем дусларым» шигыренең эчтәлеген белү, төп фикерне билгели алу.

**Материал:** Электрон дәреслек: Әдәби уку. 4 нче сыйныф. Ике кисәктә. Беренче кисәк: башлангыч гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен) / Г.Н. Мөхәрләмова, Д.М. Абдуллина. – Казан, 2023 / http://litcorpus.antat.ru/ADABI_UKU/4snf/part1/#p=0

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, иллюстрацияләр, видеоролик.

**Дәрес барышы**

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

Исәнләшү.

Уңай эмоциональ халәт тудыру.

**II. Актуальләштерү.**

Дәрес башында иң элек персонажларның әңгәмәсен укытабыз һәм укучыларны дуслык турында сөйләшүгә тартабыз. Бу вакытта

укучылар дуслык турында укылган әсәрләрен, мәкаль-әйтемнәрне искә төшерергә мөмкин.

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

Бу дәрестә «Дуслыктан зур көч юк» дип аталган тематик блокны өйрәнә башлавыбызны хәбәр итәбез.

**IV. Уку мәсьәләсен адымлап чишү.**

Зур теманы өйрәнү Бари Рәхмәтнең «Минем дусларым» исемле шигырен уку белән башланып китә. Бу вакытта видеодәрес материалыннан файдаланырга мөмкин. Шигырь белән танышып, аңлашылмаган сүзләрне ачыклаганнан соң, шигырьнең эчтәлеген билгеләгән сорауларга җавап бирүне оештырабыз. Ул сорауларга җавап табу укучылар өчен артык кыен булмас. Шигырьдәге балалар исемнәреннән чыгып, аларның төрле милләттән булуын фаразлата алабыз. Шигырь идеясенең милләтләр дуслыгы белән дә бәйле булуын төшендерәбез. Укучылар төрле милләт вәкилләренең дуслыкта, татулыкта яшәргә тиешлеген аңлыйлар.

Хат аша аралашу турында өстәмә сөйләшү оештырырга мөмкин. Предметны тирәнтен өйрәнүчеләрдән бүгенге көндәге аралашу ысуллары турында сораштырып, этикет, сөйләшү, аралашу әдәбе турында искәртәбез.

**V. Белемнәрне беренчел ныгыту.**

Лагерь тормышы турында әңгәмә үткәрәбез. Укучылар монологик сөйләм төзеп, лагерь белән бәйле истәлекләрен уртаклашалар, анда тапкан дуслары турында сөйлиләр.

Тема ахырында бирелгән «Йөз сум акчаң булганчы, йөз дустың булсачы» мәкале дәрескә нәтиҗә ясарга булышлык итә.

**VI. Өй эше бирү.**

Шигырьне сәнгатьле итеп укырга.

**VII. Рефлексия.**

Дәрестә өйрәнелгәннәргә нәтиҗә ясала.

Бәяләү, үзбәя бирелә.

**Тема**: Кадерле бүләк

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* – кадерле бүләк төшенчәсен аңлау.

*Метапредмет нәтиҗәләр* – фаразлау, уку мәсьәләсен куя белү, иптәшләренең җавапларын бәяләү, үзбәя; сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләре урнаштыру; диалог һәм әңгәмә алып бару кагыйдәләрен үтәү, үз өлешенә тигән эшне башкаруда җаваплылык хисе булдыру, үз фикерен әйтә белү.

*Предмет нәтиҗәләр* – Әминә Бикчәнтәеваның «Шыгырдавыклы башмаклар» хикәясенең эчтәлеген белү, аның буенча сорауларга җавап бирә алу.

**Материал:** Электрон дәреслек: Әдәби уку. 4 нче сыйныф. Ике кисәктә. Беренче кисәк: башлангыч гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен) / Г.Н. Мөхәрләмова, Д.М. Абдуллина. – Казан, 2023 / http://litcorpus.antat.ru/ADABI_UKU/4snf/part1/

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, иллюстрацияләр.

**Дәрес барышы**

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

Исәнләшү.

Уңай психологик халәт тудыру.

**II. Актуальләштерү.**

Өй эшен тикшерү: укучылар Бари Рәхмәтнең «Минем дусларым» шигырен сәнгатьле укыйлар.

Дәреслек персонажларының тема башында бирелгән әңгәмәсе ярдәмендә чын дуслык турында сөйләшүгә чыгабыз.

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

Алдагы этапларда эшләнгәннәрдән укучылар дәреснең темасын билгелиләр.

**IV. Уку мәсьәләсен адымлап чишү.**

Программада Әминә Бикчәнтәеваның «Шыгырдавыклы башмаклар» хикәясен өйрәнүгә 2 сәгать каралган. Беренче дәрестә

хикәянең беренче өлеше укыла. Укытучы укый башлап, укучылар дәвам итәргә мөмкин. Шулай ук электрон дәреслектә бирелгән аудиоязманы тыңлатырга мөмкин. Хикәядән өзек укылганнан соң, текстның эчтәлеге буенча сораулар бирәбез. Укучылар әсәр геройларын атыйлар, Гөлшатның гаиләсе турында сөйлиләр. Шыгырдавыклы башмакларның ни дәрәҗәдә кадерле бүләк булуын ачыклыйлар.

**V. Белемнәрне беренчел ныгыту.**

Укучылар белән кадерле бүләк турында фикер алышу үткәрергә мөмкин.

**VI. Өй эше бирү.**

Хикәяне укырга, эчтәлеген сөйләргә әзерләнергә.

**VII. Рефлексия.**

Дәрестә өйрәнелгәннәргә нәтиҗә ясала.

Бәяләү, үзбәя бирелә.

**Тема**: Шатлык та, кайгы да уртак

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* – чын дуслыкның асылына төшенү.

*Метапредмет нәтиҗәләр* – фаразлау, уку мәсьәләсен куя белү, иптәшләренең җавапларын бәяләү, үзбәя; сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләре урнаштыру; әңгәмәдә катнашу, үз фикерен әйтә белү, сөйләм ситуациясе нигезендә телдән һәм язма текстлар булдыру.

*Предмет нәтиҗәләр* – Әминә Бикчәнтәеваның «Шыгырдавыклы башмаклар» хикәясенең эчтәлеген белү, төп фикерне билгели алу.

**Материал:** Электрон дәреслек: Әдәби уку. 4 нче сыйныф. Ике кисәктә. Беренче кисәк: башлангыч гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен) / Г.Н. Мөхәрләмова, Д.М. Абдуллина. – Казан, 2023 / http://litcorpus.antat.ru/ADABI_UKU/4snf/part1/

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, иллюстрацияләр.

## Дәрес барышы

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

Исәнләшү, уңай психологик халәт тудыру.

**II. Актуальләштерү.**

Өй эшен тикшерү: хикәянең эчтәлеген искә төшерү.

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

Алмаз белән Гөлназның тема башында бирелгән әңгәмәсе ярдәмендә укучылар уку мәсьәләсен билгели алачаклар.

**IV. Уку мәсьәләсен адымлап чишү.**

«Шыгырдавыклы башмаклар» хикәясенең икенче өлеше укыла. Электрон дәреслектәге аудиоязманы тыңлатырга мөмкин. Бу өлештә Ләләнең гаиләсе турында беләбез. Гөлшатның башмакларны Ләләгә бүләк итүенә аерым игътибар бирәбез, аның бу гамәлен укучылардан бәяләтәбез. Кызларның хис-кичерешләрен ачыклыйбыз.

**V. Белемнәрне беренчел ныгыту.**

Алдагы дәрестәге чын дуслык турында сөйләшүне дәвам итеп, дәреслек персонажлары белән бергәләшеп, әлеге мәсьәлә буенча фикер алышу уздырабыз.

**VI. Өй эше бирү.**

Хикәяне укырга, эчтәлеген сөйләргә әзерләнергә, чын дуслык турында зур булмаган хикәя төзеп килергә.

**VII. Рефлексия.**

Дәрестә өйрәнелгәннәргә нәтиҗә ясала.

Бәяләү, үзбәя бирелә.

**Тема**: Дусларың гына булсын

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* – дустыңа тугры булырга кирәклекне аңлау.

*Метапредмет нәтиҗәләр* – фаразлау, укытучы ярдәмендә максатны формалаштыру, иптәшләренең җавапларын бәяләү; мәгълүмат алу, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләре урнаштыру; әңгәмәдә катнашу, үз фикерен әйтә белү.

*Предмет нәтиҗәләр* – Рөстәм Мингалимнең «Дусларың гына булсын» шигыренең эчтәлеген белү, төп фикерне билгели алу.

**Материал:** Электрон дәреслек: Әдәби уку. 4 нче сыйныф Ике кисәктә. Беренче кисәк: башлангыч гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен) / Г.Н. Мөхәрләмова, Д.М. Абдуллина. – Казан, 2023 / http://litcorpus.antat.ru/ADABI_UKU/4snf/part1/#p=0

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, иллюстрацияләр.

## Дәрес барышы

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

Исәнләшү.

Уңай эмоциональ халәт тудыру.

**II. Актуальләштерү.**

Өй эшен тикшерү. Алдагы дәрестә үткәннәрне искә төшерү. «Шыгырдавыклы башмаклар» хикәясендә сөйләнгән дуслыкның әһәмиятен билгеләп, аның көн дә кирәк булуын исбатлау.

Яңа темага кереп китү өчен, дәреслектәге персонажларның үзара сөйләшүеннән файдаланабыз.

Бу сөйләшүгә кереп китеп, укучылар дусларның ни өчен кирәк булуын билгелиләр.

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

Дәреснең темасы, максаты билгеләнә.

**IV. Уку мәсьәләсен адымлап чишү.**

Үрнәк программада Рөстәм Мингалимнең «Дусларың гына булсын» шигырен өйрәнү каралган. Шигырь күләме ягыннан зур

түгел. Ләкин анда зур, тирән мәгънә салынган фикерләр җиткерелә. Бу фикерләрне тирәнтен өйрәнүчеләр бик тиз билгели алачаклар, база өлешен генә өйрәнүчеләр өчен бу мәгънәләргә төшенү кыенлык тудырырга мөмкин, биредә аңлатып китү сорала. Тирәнтен өйрәнүчеләр өчен сөйләшүгә алып чыга торган сораулар тәкъдим ителә.

**V. Белемнәрне беренчел ныгыту.**

Дуслык турында сөйләшүне дәвам итеп, укучылар дуслыкның кадерен белергә кирәклекне дә үзләштерергә тиешләр. Бу очракта Хөрмәтле Дәреслек исеменнән сөйләнгән «Өч дус» хикәясе ярдәм итәчәк. Хикәя күләме ягыннан зур (шуңа күрә аны, нигездә, тирәнтен өйрәнүчеләргә тәкъдим итәбез), әмма бик кызыклы һәм аңа тирән мәгънәләр салынган. Гадәти тормышта очрап торган, кешеләр өчен аеруча мөһим рухи, әхлакый кыйммәтләр турында сүз алып барабыз. Ул – дуслык, тугрылык, теләктәшлек, гаделлек, киң күңеллелек. Укучыларга тасвирланган вакыйга аша малайның гамәлләрен бәяләп, үз позицияләрен белдерү нигезендә, нәтиҗә ясарга мөмкинлек тудырабыз. Шулай ук үзләрен шул ситуациягә куеп карау да мөһим, бу вакытта инде геройларның гамәлләрен аңлауга ирешәбез.

**VI. Өй эше бирү.**

Шигырьне ятларга.

**VII. Рефлексия.**

Дәрестә өйрәнелгәннәргә нәтиҗә ясала.

Бәяләү, үзбәя бирелә.

**Тема**: Яңа дус таптым

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* – кеше тормышында китапның әһәмиятенә төшенү.

*Метапредмет нәтиҗәләр* – уку мәсьәләсен куя белү, иптәшләренең җавапларын бәяләү, үзбәя; сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләре

урнаштыру; әңгәмәдә катнашу, үз өлешеңә тигән эшне башкаруда җаваплылык хисе булдыру, үз фикереңне дөрес һәм дәлилле итеп әйтү.

*Предмет нәтиҗәләр* – Хәкимҗан Халиковның «Яңа дус таптым» шигыренең эчтәлеген белү, төп фикерне аңлау.

**Материал:** Электрон дәреслек: Әдәби уку. 4 нче сыйныф. Ике кисәктә. Беренче кисәк: башлангыч гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен) / Г.Н. Мөхәрләмова, Д.М. Абдуллина. – Казан, 2023 / http://litcorpus.antat.ru/ADABI_UKU/4snf/part1/

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, иллюстрацияләр.

## Дәрес барышы

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

Исәнләшү, уңай эмоциональ халәт тудыру.

**II. Актуальләштерү.**

Өй эшен тикшерү. Дуслык әдәпләре турында сораштыру.

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

Дәреснең темасын һәм максатын билгеләү өчен персонажларның 54 биттәге диалогы белән таныштырабыз. Шуларга нигезләнеп, укучылар дәрестә нәрсә турында сүз барачагын фаразлап әйтә алачаклар.

**IV. Уку мәсьәләсен адымлап чишү.**

Хәкимҗан Халиковның «Яңа дус таптым» шигыре сәнгатьле итеп укыла, яки аудиоязмасы тыңлана. Видеодәрес материалыннан да файдаланып була. Аның буенча сорауларга җаваплар биргәндә, укучылардан тормыш белән бәйләп сөйләү сорала.

**V. Белемнәрне беренчел ныгыту.**

«Китап – безнең дустыбыз» темасына әңгәмә үткәреп була. Резеда Вәлиеваның «Акыллы дус» шигыре алда өйрәнгән шигырьгә аваздаш. тагын бер тапкыр китапның кешенең дусты булуын ассызыклыйбыз.

Сабантуй бүләге рәвешендә бирелгән «Дустың китап булса, адашмассың» мәкаленең мәгънәсенә төшенеп, нәтиҗә ясатырга була.

**VI. Өй эше бирү.**

Шигырьне сәнгатьле итеп укырга өйрәнергә.

**VII. Рефлексия.**

Дәрестә өйрәнелгәннәргә нәтиҗә ясала.

Бәяләү, үзбәя бирелә.

**Тема**: Дуслар-ахирәтләр

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* – дуслыкның кадерен белергә кирәклекне аңлау.

*Метапредмет нәтиҗәләр* – уку мәсьәләсен куя белү, фаразлау, иптәшләренең җавапларын бәяләү, бәяләү; сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләре урнаштыру; әңгәмәдә катнашу, диалог һәм әңгәмә алып бару кагыйдәләрен үтәү, үз фикереңне дөрес һәм дәлилле итеп әйтү.

*Предмет нәтиҗәләр* – Николай Сладковның «Дуслар-ахирәтләр» хикәясенең эчтәлеген белү, төп фикерне аңлау.

**Материал:** Электрон дәреслек: Әдәби уку. 4 нче сыйныф. Ике кисәктә. Беренче кисәк: башлангыч гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен) / Г.Н. Мөхәрләмова, Д.М. Абдуллина. – Казан, 2023 / http://litcorpus.antat.ru/ADABI_UKU/4snf/part1/

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, иллюстрацияләр.

**Дәрес барышы**

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

Исәнләшү.

Уңай эмоциональ халәт тудыру.

Шигырь укыла.

**Дустым**

Ялгышсам – туры юлга этәрә.
Авыр сүз әйтсәм – төзәтә.

Белмәгәнемне өйрәтә.
Шатлыгымны уртаклаша ихластан.
Борчуымны күрми калмый һичкайчан.
Дустым – миңа һәрчак терәк ул.
Андый дус һәркемгә кирәк ул.
Янәшәңдә дустың булсын дисәң гел,
Үзең дә яхшы дус була бел.

Шигырь эчтәлегенә нигезләнеп, әңгәмә үткәрәбез.

**II. Актуальләштерү.**

Өй эшен тикшерү: укучылар шигырьне сәнгатьле итеп укыйлар.

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

Дәреснең темасын һәм максатын билгеләү өчен персонажларның 57 биттәге диалогы белән таныштырабыз. Шуларга нигезләнеп, укучылар дәрестә нәрсә турында сүз барачагын фаразлап әйтә алачаклар.

**IV. Уку мәсьәләсен адымлап чишү.**

Николай Сладковның «Дуслар-ахирәтләр» исемле хикәясе укыла. Укытучы укый башлый, укучылар дәвам итә. Әсәр геройларына характеристика бирү аларны бәяләүне дә күздә тота. Дәреслектә тәкъдим ителгән проблемалы характердагы сораулар укучыларны уйлануга, эзләнүгә этәрәчәк.

**V. Белемнәрне беренчел ныгыту.**

Гөлназ белән Тургайның тема ахырында бирелгән диалогы киңәшкә колак салмыйча ялгышу турындагы әңгәмәгә нигез сала.

**VI. Өй эше бирү.**

Хикәяне укырга, эчтәлеген сөйләргә өйрәнергә.

**VII. Рефлексия.**

Дәрестә өйрәнелгәннәргә нәтиҗә ясала.
Бәяләү, үзбәя бирелә.

**Тема**: Дуслык белән көчле без (кабатлау)

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* – дуслыкның кадерен белү.

*Метапредмет нәтиҗәләр* – уку мәсьәләсен куя белү, иптәшләренең җавапларын бәяләү, үзбәя; гомумиләштерү, нәтиҗә чыгару; диалог һәм әңгәмә алып бару кагыйдәләрен үтәү, үз фикерен дәлилләп әйтә белү, сөйләм ситуациясе нигезендә телдән һәм язма текстлар булдыру.

*Предмет нәтиҗәләр* – белемнәрне гомумиләштереп системага сала алу.

**Материал:** Электрон дәреслек: Әдәби уку. 4 нче сыйныф. Ике кисәктә. Беренче кисәк: башлангыч гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен) / Г.Н. Мөхәрләмова, Д.М. Абдуллина. – Казан, 2023 / http://litcorpus.antat.ru/ADABI_UKU/4snf/part1/

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, иллюстрацияләр.

## Дәрес барышы

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

Исәнләшү.

Уңай психологик халәт тудыру.

**II. Актуальләштерү.**

Үткән дәрестә өйрәнелгәннәрне сораштыру.

Хөрмәтле Дәреслекнең бирелгән сүзләре белән таныштырабыз. Аларның мәгънәсен ачыклыйбыз.

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

Укытучы укучыларга дәрестә нәрсә эшләячәкләрен җиткерә.

**IV. Белемнәрне ныгыту.**

Дәрестә зур тема кысаларында өйрәнелгән әсәрләрне искә төшерү күздә тотыла. Дәреслектә сораулар бирелгән, аларга җавапларны укучылар укытучы белән бергәләп табалар. Укучы үзенең фикерен җиткергән вакытта, дәлилләр, мисаллар китереп барса, яхшы була.

Ризаэддин Фәхреддиннең «Дуслык әдәпләре» белән таныштырабыз, андагы һәр җөмләнең мәгънәсен ачыклап барабыз.

Шулай ук Гөлназның китапханәсендәге китаплар белән дә танышу күздә тотыла.

**V. Өйгә эш бирү.**

«Дус нинди булырга тиеш?» дигән темага хикәя төзеп килергә.

**VI. Рефлексия.**

Дәрестә өйрәнелгәннәргә нәтиҗә ясала.

Бәяләү, үзбәя бирелә.

**Тема**: Без утырткан урман үсә

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* – табигатьне яратырга, аның хәрәкәтен эчке тоемлау аша кабул итәргә өйрәнү.

*Метапредмет нәтиҗәләр* – фаразлау, укытучы ярдәмендә максатны формалаштыру, иптәшләренең җавапларын бәяләү; сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләре урнаштыру; әңгәмәдә катнашу, үз фикерен дәлилләп әйтә белү.

*Предмет нәтиҗәләр* – Зәкия Туфайлованың «Без утырткан урман» шигыренең, Роза Хафизованың «Күңел күзе» хикәясенең эчтәлеген аңлау, әсәрләрнең темасын билгели алу.

**Материал:** Электрон дәреслек: Әдәби уку. 4 нче сыйныф. Ике кисәктә. Икенче кисәк: башлангыч гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен) / Г.Н. Мөхәрләмова, Д.М. Абдуллина. – Казан, 2023 http://litcorpus.antat.ru/ADABI_UKU/4snf/part2/

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, иллюстрацияләр, видеоролик.

## Дәрес барышы

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

Укучылар белән исәнләшү, дәрескә әзерлекләрен сораштыру, дәрескә оештыру.

**II. Актуальләштерү.**

Укучыларның тормыш тәҗрибәсенә һәм алдагы сыйныфларда укыган әсәрләргә нигезләнеп, дәресне табигатьне күзәтә һәм аңлый белү турында сөйләшүдән башларга мөмкин.

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

Алдагы сөйләшү дәреслек геройларының әңгәмәсе белән кушылып китә һәм укучылар бу дәрестә табигатьне ярату һәм саклау турында сүз барачагын билгели алалар.

**IV. Уку мәсьәләсен адымлап чишү.**

Дәреснең төп өлешендә Зәкия Туфайлованың «Без утырткан урман» шигыре белән танышу күздә тотыла. Әсәрне сыйныфта укыйбыз, яки электрон дәреслектә бирелгән аудиоязмадан тыңлатабыз. Видеодәрес материалыннан да файдаланырга мөмкин. Сүзлек эше үткәрелә. Сорауларга җавап биргәндә, урманның кеше тормышындагы әһәмиятенә игътибар иттереп, бу турыда фикер алышу уздырабыз. Дәреслектә бирелгән иллюстрацияне кулланып, сөйләм телен үстерү өстендә эшләп алырга мөмкин. Шулай ук игътибарны шигырьнең төзелешенә юнәлдереп, рифмадаш сүзләрне таптырабыз, сөйләшү барышында әсәрнең сәнгатьлелеге мәсьәләсен дә читтә калдырмыйбыз.

Роза Хафизованың «Күңел күзе» хикәясе белән таныша башлаганчы, аның исеменә игътибар иттерү сорала. Укучылар арасында *күңел күзе* гыйбарәсенең мәгънәсен аңлата алучы булу-булмавы белән кызыксынырга мөмкин. Әлеге гыйбарәне аңлату сорала.

Укучылар әсәр исеменең мәгънәсен ачыклагач, аның нәрсә турында булуын фаразлый алалар. Аларга дәреслектәге рәсем дә берникадәр ярдәм итәчәк.

Алга таба хикәя белән танышу, сүзлек эше һәм сорауларга җавап бирү күздә тотыла. Сорауларга җавап бирү хикәяне тулысынча аңларга ярдәм итәчәк. 7, 8 сорауларга җавап хикәянең төп фикерен ачып бирер: *маңгай күзе белән күрмәгән нәрсәләрне күңел күзе белән күреп була икән.* Камил кош оясын маңгай күзе белән күрмәде, әмма күңеле белән тойды, акылы белән аңлады.

Кошның ни әйтергә теләгәнен төшенде. Димәк, күңел күзе белән күрү – хакыйкатьне күңелең белән тоеп, акыл белән кабул итү икән ул. Дәреснең бу этабыннан соң, хикәяне өлешләргә бүләргә, эчтәлеген сөйләү өчен план төзергә мөмкин.

Вакыт калса, укучыларның тормыш тәҗрибәсенә һәм элеккеге елларда өйрәнелгән әсәрләргә таянып, туган ягыбыздагы кошлар, табигатьне саклау турында әңгәмәгә оештырырга мөмкин. Бу балаларны күзәтүчән булырга, табигатьне күңел күзе белән күрергә өйрәтер.

**V. Белемнәрне беренчел ныгыту.**

Укучыларның әзерлекләре югары булганда, гомумиләштерелгән нәтиҗәне үзләре үк ясый алыр, бу очракта укытучының юнәлеш бирүе генә сорала. Сүз байлыгы һәм табигать белән якыннан танышлыклары азрак булган укучылар хикәянең эчтәлегенә кагылышлы сораулар аша нәтиҗә чыгарырга тиеш.

**VI. Өйгә эш бирү.**

Шигырьне сәнгатьле укырга өйрәнергә, планга нигезләнеп, хикәянең эчтәлеген сөйләргә өйрәнергә.

**VII. Рефлексия.**

Дәрестә өйрәнелгәннәргә нәтиҗә ясала.

Бәяләү, үзбәя бирелә.

**Тема**: Тукран малае Шуктуган

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* – табигать матурлыгын күрә, соклана белү.

*Метапредмет нәтиҗәләр* – фаразлау, укытучы ярдәмендә максатны формалаштыру, иптәшләренең җавапларын бәяләү; сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләре урнаштыру; әңгәмәдә катнашу, диалог һәм әңгәмә алып бару кагыйдәләрен үтәү, үз фикерен дәлилләп әйтә белү.

*Предмет нәтиҗәләр* – Җәвад Тәрҗемановның «Тукран малае Шуктуган» хикәясенең эчтәлеген аңлау, сорауларга җавап бирә алу.

**Материал:** Электрон дәреслек: Әдәби уку. 4 нче сыйныф. Ике кисәктә. Икенче кисәк: башлангыч гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен) / Г.Н. Мөхәрләмова, Д.М. Абдуллина. – Казан, 2023 / http://litcorpus.antat.ru/ADABI_UKU/4snf/part2/

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, иллюстрацияләр.

## Дәрес барышы

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

Укучылар белән исәнләшү, дәрескә әзерлекләрен сораштыру, дәрескә оештыру.

**II. Актуальләштерү.**

Өй эшен тикшерү: Зәкия Туфайлованың «Без утырткан урман» шигырен сәнгатьле итеп укытабыз, Роза Хафизованың «Күңел күзе» хикәясенең эчтәлеген искә төшерәбез. Урман турында сөйләшүебезне дәвам итеп, дәреслектә тема башында бирелгән әңгәмәне укыйбыз.

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

Алдагы этапта эшләгәннәргә нигезләнеп, укучылар дәрестә сүзнең нәрсә турында барачагын билгели алачаклар.

**IV. Уку мәсьәләсен адымлап чишү.**

Бу дәрестә Җәвад Тәрҗемановның «Тукран малае Шуктуган» хикәясе белән таныша башлыйбыз. Беренче өлеше укыла. Укытучы үзе укый башлый, укучылар дәвам итә. Чылбырлап укытырга мөмкин. Әсәрдә укучыларга аңлашылмаган сүзләр дә очравы бар. Шуңа күрә сүзлек эшенә аерым тукталабыз.

Сорауларга җавап биргәндә игътибарны Тук-тук бабай һәм Шуктуган образларын характерлауга юнәлтәбез. Иң элек тукран турында белешмә биреп китү сорала. Тукранның нинди кош

булуы, кайда яшәве, нәрсә белән һәм ничек туклануы турында сөйләсәк, укучылар бу кошны беркадәр күз алдына китерә алачак.

**V. Белемнәрне беренчел ныгыту.**

Кошларның табигатьтәге функцияләре, файдасы турында әңгәмә корырга мөмкин.

**VI. Өйгә эш бирү.**

Хикәянең эчтәлеген сөйләргә өйрәнергә.

**VII. Рефлексия.**

Дәрестә өйрәнелгәннәргә нәтиҗә ясала.

Бәяләү, үзбәя бирелә.

**Тема**: Шуктуган сабак алды

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* – олыларның сүзен тыңларга кирәклекне аңлау.

*Метапредмет нәтиҗәләр* – фаразлау, укытучы ярдәмендә максатны формалаштыру, иптәшләренең җавапларын бәяләү; сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләре урнаштыру; әңгәмәдә катнашу, үз фикерен дәлилләп әйтә белү.

*Предмет нәтиҗәләр* – Җәвад Тәрҗемановның «Тукран малае Шуктуган» хикәясенең эчтәлеген аңлау, сорауларга җавап бирә алу.

**Материал:** Электрон дәреслек: Әдәби уку. 4 нче сыйныф. Ике кисәктә. Икенче кисәк: башлангыч гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен) / Г.Н. Мөхәрләмова, Д.М. Абдуллина. – Казан, 2023 / http://litcorpus.antat.ru/ADABI_UKU/4snf/part2/

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, иллюстрацияләр.

**Дәрес барышы**

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

Исәнләшү.

Уңай эмоциональ халәт тудыру.

**II. Актуальләштерү.**

Өй эшен тикшерү: Җәвад Тәрҗемановның «Тукран малае Шуктуган» хикәясенең беренче өлешенең эчтәлеген сөйләү, белемнәрне искә төшерү.

Дәреслек персонажларының әңгәмәсе белән таныштыру.

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

Алдагы этапта эшләнгәннәргә нигезләнеп, укучылар дәрестә тукранның маҗаралары турында сүз барачагын җиңел билгели алачаклар.

**IV. Уку мәсьәләсен адымлап чишү.**

Җәвад Тәрҗемановның «Тукран малае Шуктуган» хикәясенең икенче өлеше укыла. Бу өлешне укучылар укытучы белән берлектә укып чыкканнан соң, аңлашылмаган сүзләр барлана, аларның мәгънәләре аңлатыла.

Эчтәлек буенча сорауларга җавап бирү барышында укучылардан нинди яңа мәгълүматлар алулары турында сораштырабыз. Шулай ук Шуктуганның гамәлләрен бәяләргә кушабыз. Шуктуганның урмандагы җәнлекләргә, ярканатка охшарга тырышып, нәрсәгә ирешүе турында сораштырабыз. Бу Шуктуганны тулырак характерларга һәм нәтиҗә ясарга мөмкинлек бирәчәк.

**V. Белемнәрне беренчел ныгыту.**

Өлкәннәрнең сүзен тыңламауның нинди нәтиҗәләргә китерәчәге турында фикер алышу үткәрергә мөмкин.

**VI. Өйгә эш бирү.**

Хикәянең укылган өлешенең эчтәлеген сөйләргә өйрәнергә.

**VII. Рефлексия.**

Дәрестә өйрәнелгәннәргә нәтиҗә ясала.

Бәяләү, үзбәя бирелә.

**Тема**: Ялгышу түгел, ялгышыңны танымау начар

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* – табигатькә сакчыл карау.

*Метапредмет нәтиҗәләр* – фаразлау, укытучы ярдәмендә максатны формалаштыру, иптәшләренең җавапларын бәяләү; сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләре урнаштыру, тамга-символик чараларны куллану; әңгәмәдә катнашу, диалог һәм әңгәмә алып бару кагыйдәләрен үтәү, үз фикерен дәлилле әйтә белү, сөйләм ситуациясе нигезендә телдән һәм язма текстлар булдыру.

*Предмет нәтиҗәләр* – Җәвад Тәрҗемановның «Тукран малае Шуктуган» хикәясенең эчтәлеген аңлау, төп фикерне билгеләү.

**Материал:** Электрон дәреслек: Әдәби уку. 4 нче сыйныф. Ике кисәктә. Икенче кисәк: башлангыч гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен) / Г.Н. Мөхәрләмова, Д.М. Абдуллина. – Казан, 2023 http://litcorpus.antat.ru/ADABI_UKU/4snf/part2/

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, иллюстрацияләр.

**Дәрес барышы**

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

Исәнләшү.

Уңай эмоциональ халәт тудыру.

**II. Актуальләштерү.**

Өй эшен тикшерү: Җәвад Тәрҗемановның «Тукран малае Шуктуган» хикәясенең икенче өлешенең эчтәлеген сөйләп, белемнәрне искә төшерү.

Дәреслек персонажларының тема башында бирелгән әңгәмәсе белән таныштыру.

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

Хөрмәтле Дәреслек биргән сорауга җавап эзләп, укучыларны фаразлатабыз.

**IV. Уку мәсьәләсен адымлап чишү.**

Әкиятнең өченче өлеше укыла. Укытучы укый башлый, укучылар дәвам итә. Тексттан соң бирелгән сораулар әкиятнең эчтәле-

ген ачыклауга да, геройларны характерлауга да юнәлдерелгән. Биредә әсәрнең төп фикерен билгеләү әһәмиятле: табигатьне ярату һәм аңа соклану гына аз, аны саклау мөһим, ә моның өчен күп тырышлык кую сорала. Әлбәттә, без ялгышырга да мөмкин, ләкин һәлакәтне булдырмау өчен ялгышыңны үз вакытында танырга кирәк, дияргә тели автор.

Укучылар әдәби әкият жанры белән таныш, шуңа күрә бу әсәрнең дә шушы жанрга каравын билгеләү алар өчен артык авыр булмачак.

**V. Белемнәрне беренчел ныгыту.**

Урманны саклауга үзебезнең нинди өлеш кертә алуыбыз турында әңгәмә оештырсак яхшы була.

**VI. Өйгә эш бирү.**

Хикәянең укылган өлешенең эчтәлеген сөйләргә өйрәнергә, эчтәлек буенча рәсем ясарга.

**VII. Рефлексия.**

Дәрестә өйрәнелгәннәргә нәтиҗә ясала.

Бәяләү, үзбәя бирелә.

**Тема**: Агачлар да авырый

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* – табигатьне яратырга, аңа сакчыл карау зарурлыгын аңлау.

*Метапредмет нәтиҗәләр* – фаразлау, укытучы ярдәмендә максатны формалаштыру, иптәшләренең җавапларын бәяләү; сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләре урнаштыру; әңгәмәдә катнашу, диалог һәм әңгәмә алып бару кагыйдәләрен үтәү, үз фикерен дәлилләп әйтә белү.

*Предмет нәтиҗәләр* – Зәкәрия Әхмәровның «Агачлар да авырый» хикәясенең эчтәлеген аңлау, әсәрләрнең темасын билгели алу.

**Материал:** Электрон дәреслек: Әдәби уку. 4 нче сыйныф. Ике кисәктә. Икенче кисәк: башлангыч гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен) / Г.Н. Мөхәрләмова, Д.М. Абдуллина. – Казан, 2023 / http://litcorpus.antat.ru/ADABI_UKU/4snf/part2/

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, иллюстрацияләр, видеоролик.

### Дәрес барышы

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

Укучылар белән исәнләшү, дәрескә әзерлекләрен сораштыру, дәрескә оештыру.

**II. Актуальләштерү.**

Дәресне алда өйрәнелгән теманың дәвамы буларак оештырабыз. Өй эшен тикшерү барышында укучылар «Тукран малае Шуктуган» хикәясе буенча ясаган рәсемнәре белән таныштыралар, әсәрнең эчтәлеген искә төшерәләр, табигатьне саклауда мөмкин булган чаралар турында сөйләшәләр.

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

Алдагы сөйләшү дәреслек персонажларының әңгәмәсе белән кушылып китә һәм укучылар бу дәрестә нәрсә турында сүз барачагын билгели алалар.

**IV. Уку мәсьәләсен адымлап чишү.**

Дәрестә Зәкәрия Әхмәровның «Агачлар да авырый» хикәясе белән танышу күздә тотыла. Әсәрне сыйныфта укыйбыз, яки электрон дәреслектә бирелгән аудиоязмадан тыңлатабыз. Видеодәрес материалыннан да файдаланырга мөмкин. Сүзлек эше үткәрелә. Сорауларга җавап биргәндә, кызның хис-кичерешләрен, аның сәбәпләрен ачыклауга игътибар итәбез. Гомумән, укучылар хикәянең эчтәлегенә кагылышлы сораулар аша нәтиҗә чыгарырга тиеш була. Дәреслектә бирелгән иллюстрацияне кулланып, сөйләм телен үстерү өстендә эшләп алырга мөмкин.

**V. Белемнәрне беренчел ныгыту.**

«Табигатькә ничек ярдәм итеп була?» дигән темага фикер алышу уздырырга була.

Шулай ук «Сабантуй бүләге» рәвешендә бирелгән *Яратып эшләгән эш шатлык китерә* мәкален файдаланып, әңгәмә үткәрсәк тә була.

**VI. Өйгә эш бирү.**

Хикәянең эчтәлеген сөйләргә өйрәнергә.

**VII. Рефлексия.**

Дәрестә өйрәнелгәннәргә нәтиҗә ясала.

Бәяләү, үзбәя бирелә.

**Тема**: Яхшылык кире кайта

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* – яхшы күңелле, ярдәмчел булырга кирәклекне, яхшылыкның һәрвакыт яхшылыкка этәрүен аңлау, яхшылыкка яхшылык белән җавап бирү зарурлыгын төшенү.

*Метапредмет нәтиҗәләр* – уку мәсьәләсен куя белү, бәяләү; тамга-символик чараларны куллану, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләре урнаштыру; әңгәмәдә катнашу, диалог һәм әңгәмә алып бару кагыйдәләрен үтәү, үз фикерен дәлилләп әйтә белү.

*Предмет нәтиҗәләр* – Әхсән Баянның «Яхшылык кире кайта» хикәясенең эчтәлеген аңлау, темасын һәм төп фикерне билгели алу.

**Материал:** Электрон дәреслек: Әдәби уку. 4 нче сыйныф. Ике кисәктә. Икенче кисәк: башлангыч гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен) / Г.Н. Мөхәрләмова, Д.М. Абдуллина. – Казан, 2023 / http://litcorpus.antat.ru/ADABI_UKU/4snf/part2/

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, иллюстрацияләр.

## Дәрес барышы

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

Укучылар белән исәнләшү, дәрескә әзерлекләрен сораштыру, дәрескә оештыру.

**II. Актуальләштерү.**

Алдагы дәрестә «Агачлар да авырый» хикәясен өйрәнүне истә тотып, табигатькә сакчыл караш булдыру зарурлыгын кабат искә төшерергә һәм кеше дә ярдәмгә мохтаҗ булырга мөмкин икәнлегенә дә игътибарны юнәлтергә була.

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

Алга таба дәреслек геройларының сөйләшүе ярдәмендә уку мәсьәләсен куярга мөмкин. Нур дәреслектәге рәсемнәргә игътибар итәргә куша. Рәсемнәрне карагач, укучылар сөйләшүнең яхшылык турында булачагын әйтеп бирә алырлар.

**IV. Уку мәсьәләсен адымлап чишү.**

Әхсән Баянның «Яхшылык кире кайта» хикәясен укырга әзерлек этабы буларак, яхшылык турында, кемнең нинди яхшылык эшли алуы турында әңгәмә корырга була. Укучыларның кошларга җимлек кую һәм башкалар турында искә төшерүләре яхшы.

Хикәяне уку, сүзлек белән эш, сорауларга җавап бирүне укытучы үзе дәреснең максатына яраклаштырып уздыра. Хикәянең эчтәлеге авыр түгел. Сорауларга җаваплар табу да кыенлык тудырмас. Дәреслек геройларының әңгәмәсе хикәянең эчтәлеген кабул итүдә, аның төп фикерен ачуда ачкыч булып тора. Чыннан да, урамдагы этләргә якын бару, аларны өйгә алып кайтасы ризыклар белән тукландырып йөрү хәзер мөмкин дә түгелдер. Хикәяне укыгач, укучы икенче бер хакыйкатькә төшенер, үзе өчен шуны ачар: яхшылыкка без һәрвакыт яхшылык белән җавап бирергә тиеш. Яхшылыкны хәтта этләр дә аңлый, алар да яхшылыкны яхшылык белән кайтара. Ә без, кешеләр, яхшылыкка һәрвакыт яхшылык белән генә җавап бирергә тиеш икәнен оныт-

мыйбызмы? Укучылар алдагы тәҗрибәләренә нигезләнеп, тәмле сүзләр әйтешү, кешеләргә игътибарлы булу, бер-береңне хөрмәт итү кирәклекне исләренә төшерәләр.

**V. Белемнәрне беренчел ныгыту.**

Ярдәмчеллек, игелек кылу һәм яхшылыкка бары яхшылык белән генә җавап бирү кирәклеген кабат мисаллар белән дәлилләп, белемнәрне ныгытырга мөмкин.

**VI. Өй эше бирү.**

Хикәянең эчтәлеген эзлекле итеп сөйләргә өйрәнергә; хикәянең геройларына (малайга һәм эткә) бәя бирергә.

**VII. Рефлексия.**

Дәрестә өйрәнелгәннәргә нәтиҗә ясала.

Бәяләү, үзбәя бирелә.

**Тема**: Шәфкатьле бала

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* – табигатьне яратырга, аны күрә белергә өйрәнү, табигатькә сакчыл карау зарурлыгын аңлау.

*Метапредмет нәтиҗәләр* – укытучы ярдәмендә максатны формалаштыру, иптәшләренең җавапларын бәяләү; сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләре урнаштыру; әңгәмәдә катнашу, үз фикерен дәлилләп әйтә белү, сөйләм ситуациясе нигезендә телдән һәм язма текстлар булдыру.

*Предмет нәтиҗәләр* – Шәүкәт Галиевнең «Курыкма, тимим», Фәнис Яруллинның «Серле көндәлек» шигырьләренең эчтәлеген аңлау, әсәрләрнең темасын билгели алу.

**Материал:** Электрон дәреслек: Әдәби уку. 4 нче сыйныф. Ике кисәктә. Икенче кисәк: башлангыч гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен) / Г.Н. Мөхәрләмова, Д.М. Абдуллина. – Казан, 2023 / http://litcorpus.antat.ru/ADABI_UKU/4snf/part2/

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, иллюстрацияләр, видеоролик.

## Дәрес барышы

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

Укучылар белән исәнләшү, дәрескә әзерлекләрен сораштыру, дәрескә оештыру.

**II. Актуальләштерү.**

Өй эшен тикшерү: укучылар хикәянең эчтәлеген сөйлиләр, хикәя геройларына әзерләп килгән бәяләре белән таныштыралар.

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

Дәреслек персонажларының тема башында бирелгән әңгәмәсе укучыларга бу дәрестә нәрсә турында сүз барачагын билгеләргә ярдәм итәчәк.

**IV. Уку мәсьәләсен адымлап чишү.**

Дәреснең төп өлешендә Шәүкәт Галиевнең «Курыкма, тимим» шигыре белән белән танышу күздә тотыла. Әсәрне сыйныфта укыйбыз, яки электрон дәреслектә бирелгән аудиоязманы тыңлатабыз. Видеодәрес материалыннан да файдаланырга мөмкин. Сүзлек эше үткәрелә. Сорауларга җавап биргәндә, шигырьнең үткәрелгән төп фикерен ачыклауга йөз тотабыз. Төп фикернең кайсы юлларда чагылыш табуын таптырып укытабыз, нәтиҗә ясаганда, әлеге фикернең Әхсән Баянның «Яхшылык кире кайта» хикәясендә чагылыш табуын билгелэтәбез. Кабатланып килгән урыннарга игътибар иттереп, биредә кабатлауның функцияләрен ачыклыйбыз.

Бу дәрестә шулай ук Фәнис Яруллинның «Серле көндәлек» шигыре белән танышу да күздә тотыла. Әсәргә кереш әңгәмә белән танышканнан соң, шигырь укыла, аннан алынган беренче тәэсир ачыклана. Эзләнү характерындагы соруларга җавап биргәндә, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләре урнаштыру гамәле формалаша. Шигырьдән соң бирелгән сораулар сурәтләү чарасы буларак метафораны аңлауга юнәлеш бирә. Алга таба, укучылар әлеге төшенчәне җиңел үзләштерә, мөстәкыйль рәвештә метафорага мисаллар китерә алачаклар.

**V. Белемнәрне беренчел ныгыту.**

Сабантуй бүләгендә бирелгән табигатькә сакчыл караш тәрбияләүгә юнәлтелгән киңәшләр белән танышу әңгәмәгә алып чыга.

**VI. Өйгә эш бирү.**

Шәүкәт Галиевнең «Курыкма, тимим» шигырен ятларга, Фәнис Яруллинның «Серле көндәлек» шигырен сәнгатьле итеп укырга өйрәнергә.

**VII. Рефлексия.**

Дәрестә өйрәнелгәннәргә нәтиҗә ясала.

Бәяләү, үзбәя бирелә.

**Тема**: Табигать китабы (кабатлау).

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* – табигать һәм кеше бердәмлеген аңлап кабул итәргә өйрәнү, табигатьне саклау бурычын аңлау.

*Метапредмет нәтиҗәләр* – уку мәсьәләсен куя белү, иптәшләренең җавапларын бәяләү; сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләре урнаштыру, гомумиләштерә һәм нәтиҗә ясый белү; диалог һәм әңгәмә алып бару кагыйдәләрен үтәү, үз фикерен әйтә һәм дәлилли белү.

*Предмет нәтиҗәләр* – «Табигать китабы» дип аталган зур темада үзләштерелергә тиешле әһәмиятле өлешләрне хәтердә калдыру, сорауларга җавап бирә белү.

**Материал:** Электрон дәреслек: Әдәби уку. 4 нче сыйныф. Ике кисәктә. Икенче кисәк: башлангыч гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен) / Г.Н. Мөхәрләмова, Д.М. Абдуллина. – Казан, 2023 / http://litcorpus.antat.ru/ADABI_UKU/4snf/part2/

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, иллюстрацияләр.

## Дәрес барышы

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

Укучылар белән исәнләшү, дәрескә әзерлекләрен сораштыру, дәрескә оештыру.

**II. Актуальләштерү.**

Алдагы дәресләрдә нинди зур тема өйрәнүләрен, нинди әсәрләр укуларын тиз генә искә төшереп алу.

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

Актуальләштерү өлешендәге сөйләшү ярдәмендә бу дәреснең өйрәнгәннәрне искә төшерү, нәтиҗә ясау дәресе булачаган билгелиләр. Укытучы аның темасын ачык итеп әйтә.

**IV. Белемнәрне ныгыту.**

Кабатлау дәресен ничек уздыру укытучы ихтыярына бәйле. Ул бары үткән материалдан иң әһәмиятле нәрсәләрне хәтердә ныгытып куюга хезмәт итәргә, гомуми нәтиҗә чыгарырга булышырга гына тиеш. Табигать темасын кабатлаганда, укылган әсәрләрдән иң әһәмиятле өзекләрне алып, аларның һәрберсен бер тукталыш итеп билгеләргә һәм бу тукталышларда әсәр эчтәлегенә, геройны бәяләүгә, тема һәм төп фикерне ачуга караган сорауларга җавап табарга мөмкин. Дәреслек геройларының җаваплары рәвешендә дә оештырырга була. Кабатлауга ярдәм итәрдәй биремнәр дәреслектә дә бар.

Кабатлау укучыга зур теманы бербөтен итеп хәтердә калдырырга булышырга тиеш.

Үтелгән теманы гомумиләштереп, нәтиҗә ясала.

Табигать темасына караган китаплар белән танышу, аларны укырга тәкъдим итү дә зарур.

**V. Өй эше бирү.**

Иң яраткан герой, иң яраткан әсәр яки бу темага үзең укыган берәр әсәр яки аның герое турында дәфтәргә язып килергә.

**VI. Рефлексия.**

Дәрестә өйрәнелгәннәргә нәтиҗә ясала.

Бәяләү, үзбәя бирелә.

**Тема**: Бәйрәм бүген

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр – бәйрәм рухы* гыйбарәсен аңлау.

*Метапредмет нәтиҗәләр* – фаразлау, уку мәсьәләсен куя белү, иптәшләренең җавапларын бәяләү, үзбәя; сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләре урнаштыру; әңгәмәдә катнашу, үз фикерен әйтә белү.

*Предмет нәтиҗәләр* – Нур Гайсинның «Бүген бәйрәм», Җәүдәт Дәрзаманның «Солдат булдым» шигырьләренең эчтәлеген белү, аның буенча сорауларга җавап бирә алу.

**Материал:** Электрон дәреслек: Әдәби уку. 4 нче сыйныф. Ике кисәктә. Икенче кисәк: башлангыч гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен) / Г.Н. Мөхәрләмова, Д.М. Абдуллина. – Казан, 2023 / http://litcorpus.antat.ru/ADABI_UKU/4snf/part2/

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, иллюстрацияләр.

## Дәрес барышы

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

Исәнләшү.

Уңай психологик халәт тудыру.

Тургайның дәреслектә бирелгән сәламләү сүзләрен укытабыз.

**II. Актуальләштерү.**

Бу дәрестә «Күңелле бәйрәмнәр» дип аталган яңа теманы башлап җибәрү күздә тотыла. Габдулла Тукайның «Бәйрәм бүген» шигырен укырга, яки аудиоязмадан шул шигырьне яки җырны тыңлатырга мөмкин. Видеодәрес материалыннан да файдаланып була. Әлеге әсәргә нигезләнеп, бәйрәмнәр турында әңгәмә үткәрсәк яхшы була.

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

Укучылар дәреслек персонажларының диалогы белән танышкач, дәрестә сүз нәрсә турында барачагын фаразлый алачаклар.

**IV. Уку мәсьәләсен адымлап чишү.**

Нур Гайсинның «Бүген бәйрәм» шигыре укыла, электрон дәреслектә бирелгән аудиоязманы да тыңлатырга мөмкин. Шуннан соң укучылар беренче тәэсирләре белән уртаклашалар. Сорауларга җавап биргәндә илне саклау – һәр кешенең бурычы, дигән фикернең үзләштерелергә тиешлеген онытмыйбыз. Нурның Солдат булу өчен нәрсәләр кирәк? дигән соравына җавап бирүне бергәләшеп, әңгәмә рәвешендә оештырырга мөмкин.

Бу дәрестә татар мәктәбендә укучылар өчен тагын бер әсәрне – Җәүдәт Дәрзаманның «Солдат булдым» шигырен уку күздә тотыла. Шигырь укылганнан соң, сорауларга җаваплар алына.

**V. Белемнәрне беренчел ныгыту.**

Ә сез солдат булырга әзерме? дигән сорау биреп, укучыларны фикерләшүгә алып чыгабыз.

Бу бәйрәмне өйләрдә ничек үткәрүләре турында сорашырга мөмкин.

Тема ахырында «Сабантуй бүләге» рәвешендә бирелгән мәкаль дәрескә нәтиҗә ясарга мөмкинлек бирә.

**VI. Өй эше бирү.**

Шигырьләрне сәнгатьле итеп укырга өйрәнергә.

**VII. Рефлексия.**

Дәрестә өйрәнелгәннәргә нәтиҗә ясала.

Бәяләү, үзбәя бирелә.

**Тема**: Әниләр бәйрәме

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр – бәйрәм рухы* дигән төшенчәне аңлау. Әниләргә, әбиләргә мәхәббәт, хөрмәт хисенә төшенү.

*Метапредмет нәтиҗәләр* – фаразлау, уку мәсьәләсен куя белү, иптәшләренең җавапларын бәяләү, үзбәя; сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләре урнаштыру; әңгәмәдә катнашу, үз фикерен әйтә белү.

*Предмет нәтиҗәләр* – Саҗидә Сөләймانованың «Әниләр бәйрәме» шигыренең, Нәби Дәүлинең «Минем кадерле әбием» хикәясенең эчтәлеген белү, аның буенча сорауларга җавап бирә алу.

**Материал:** Электрон дәреслек: Әдәби уку. 4 нче сыйныф. Ике кисәктә. Икенче кисәк: башлангыч гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен) / Г.Н. Мөхәрләмова, Д.М. Абдуллина. – Казан, 2023 / http://litcorpus.antat.ru/ADABI_UKU/4snf/part2/

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, иллюстрацияләр, видеоролик.

## Дәрес барышы

### I. Оештыру-мотивлаштыру.

Исәнләшү.

Уңай психологик халәт тудыру.

### II. Актуальләштерү.

Өй эше тикшерелә, шигырьләр сәнгатьле итеп укыла, алда өйрәнгән тема буенча сораулар биреп, белгәннәр искә төшерелә.

Рафис Корбанның шигырен уку.

**Бәйрәм бүген**

Күтәренке күңелле,
Бар да көләч, шат бүген.
Күктә кояш елмая,
Яшералмый шатлыгын.

Тып-тып тама тамчылар,
Җырлап бәйрәм көенә.
«Бәйрәм бүген! дип, гүя
Тамчылар да сөенә.

Җырлыйсы килеп кенә
Тора бүген безнең дә,
Көтеп алган бәйрәме
Бүген һәммәбезнең дә.

Җыр күтәрә күңелне,
Бар да көләч, шат бүген.
Бүген Әни бәйрәме,
Сигезенче март бүген.

*Рафис Корбан*

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

Алмазның бәйрәмгә әзерләнү турындагы сүзләре белән таныштырабыз. Бу эш теманы билгеләргә ярдәм итәчәк.

**IV. Уку мәсьәләсен адымлап чишү.**

Дәреснең төп өлешен Саҗидә Сөләймpraнованың «Әниләр бәйрәме» шигыре белән танышу алып тора. Укучылар шигырьне укыйлар. Бу очракта видеодәрес материалын кулланырга мөмкин. Текст буенча сорауларга җавап бирү барышында шигырьнең эчтәлеге билгеләнә, шигырь героеның хисләре ачыклана.

*Күңел пакьлеге* дигән төшенчә укучыларга аңлашылып бетмәскә мөмкин, шуңа күрә аны аңлатып китү сорала. Нур бу очракта да укучыларга ярдәмгә килә.

Тирәнтен өйрәнүчеләргә авыррак сораулар бирелә. 8 мартның нинди бәйрәм булуын, бөтен дөньяда аны ничек бәйрәм итүләрен ачыклатабыз. Мәктәптә ничек бәйрәм ителүе турында да сөйләтеп була.

Шулай ук бу дәрес кысаларында Нәби Дәүлинең «Минем кадерле әбием» хикәясен уку каралган. Традицион рәвештә әсәрне укып, сорауларга җаваплар бирдерәбез.

**V. Белемнәрне беренчел ныгыту.**

Нурның «Әниләргә котлау сүзләре әзерләргә кирәк», дигән сүзләренә игътибар иттерәбез. 8 март бәйрәме уңаеннан әниләргә, дәү әниләргә, апаларга, сеңелләргә нинди теләкләр теләп була? Шул турыда әңгәмә оештыра алабыз.

**VI. Өй эше бирү.**

Шигырьне ятларга.

**VII. Рефлексия.**

Дәрестә өйрәнелгәннәргә нәтиҗә ясала.

Бәяләү, үзбәя бирелә.

**Тема**: Кояш көлә – Нәүрүз килә

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* – Нәүрүз бәйрәменең төрки халыкларның уртак бәйрәме булуына төшенү.

*Метапредмет нәтиҗәләр* – укытучы ярдәмендә максатны формалаштыру, үзбәя; мәгълүмат алу, тамга-символик чараларны куллану, иҗади күзаллау, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләре урнаштыру; әңгәмәдә катнашу, үз фикерен әйтә белү.

*Предмет нәтиҗәләр* – Роза Хафизованың «Нәүрүз килә» шигыренең эчтәлеген белү, Нәүрүз бәйрәменең мәгънәсенә төшенү.

**Материал:** Электрон дәреслек: Әдәби уку. 4 нче сыйныф. Ике кисәктә. Икенче кисәк: башлангыч гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен) / Г.Н. Мөхәрләмова, Д.М. Абдуллина. – Казан, 2023 / http://litcorpus.antat.ru/ADABI_UKU/3snf/part1/

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, иллюстрацияләр.

## Дәрес барышы

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

Исәнләшү.

Уңай психологик халәт тудыру.

**II. Актуальләштерү.**

Өй эшен тикшерү.

Дәреслек персонажларының әңгәмәсен укытабыз. Укучыларның Нәүрүз бәйрәме турында белемнәрен актуальләштерәбез.

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

Дәреснең темасы, максаты билгеләнә.

**IV. Уку мәсьәләсен адымлап чишү.**

Дәреслектә Роза Хафизованың «Нәүрүз килә» исемле шигыре тәкъдим ителә. Сәнгатьле итеп укып чыкканнан соң, укучылар беренче тәэсирләре белән уртаклашалар, аңлашылмаган сүзләрне барлап, мәгънәләрен ачыклыйлар. Шигырь тексты буенча сорауларга җавап биргәндә, укучыларның Нәүрүз белән бәйле үз тәэсирләренә, истәлекләренә таянып эшләргә кирәк. Шулай ук

туган ил, туган җир образлары белән дә бәйләп сөйлибез. Нәүрүз бәйрәмен яз белән бәйләп, төп игътибарны аның мәгънәсенә, ничек үткәрелүенә юнәлтәбез, бу бәйрәм белән бәйле такмакларны укытабыз. «Нәүрүз мөбарәк булсын!» сүзләренең мәгънәсен дә аңлатырга була. Бу очракта Дәреслек сүзләре (54–55 битләр) ярдәмгә килә. Әлбәттә, әлеге мәгълүмат белән генә чикләнеп калмыйбыз, Нәүрүз бәйрәме белән бәйле фоторәсемнәрне һәм видеоматериалларны күрсәтеп була.

**V. Белемнәрне беренчел ныгыту.**

Биредә Нәүрүзнең төрки халыкларның уртак бәйрәме булуын искәртәбез. Дәреслектә (55 бит) бирелгән фоторәсемнәргә нигезләнеп, бу бәйрәмнең кайсы халыкларда үткәрелүен билгеләтәбез.

Теманың ахырында бирелгән *Яз җилкенсәң – яшәртә, көз җилкенсәң – көрәйтә* мәкале буенча сөйләшү үткәреп була.

**VI. Өй эше бирү.**

Шигырьне сәнгатьле итеп укырга, Нәүрүз темасына рәсем ясарга кушып була.

**VII. Рефлексия.**

Дәрестә өйрәнелгәннәргә нәтиҗә ясала.

Бәяләү, үзбәя бирелә.

**Тема**: Сабан туе, хезмәт туе, шатлык һәм бәхет туе

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* – Сабантуй бәйрәменең матурлыгын, күңеллелеген күрә белү; хәрәмләшү төшенчәсе, аның зыянын аңлау.

*Метапредмет нәтиҗәләр* – укытучы ярдәмендә максатны формалаштыру, иптәшләренең җавапларын бәяләү, үзбәя; сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләре урнаштыру, мөстәкыйль рәвештә яисә укытучы тәкъдим иткән тикшерү ысулы нигезендә ышанычлы

һәм төгәл булмаган мәгълүматны танып белү; әңгәмәдә катнашу, үз фикерен дәлилләп җиткерә белү.

*Предмет нәтиҗәләр* – Ркаил Зәйдулланың «Сабантуй аланында» хикәясенең, Эльмира Шәрифуллинаның «Сабантуй» шигыренең эчтәлеген белү, аның буенча сорауларга җавап бирә белү.

**Материал:** Электрон дәреслек: Әдәби уку. 4 нче сыйныф. Ике кисәктә. Икенче кисәк: башлангыч гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен) / Г.Н. Мөхәрләмова, Д.М. Абдуллина. – Казан, 2023 / http://litcorpus.antat.ru/ADABI_UKU/4snf/part2/

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, иллюстрацияләр, видеоролик.

## Дәрес барышы

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

Исәнләшү.

Уңай эмоциональ халәт тудыру.

Дәресне Сабантуй җырын тыңлатып башлап җибәрергә мөмкин.

**II. Актуальләштерү.**

Өй эшен тикшерү: шигырь сәнгатьле итеп укыла, өйдә ясап килгән рәсемнәрдән күргәзмә оештырыла.

Темага кереп китәргә, гадәттәгечә, персонажларның әңгәмәсе ярдәм итә. Аларның Сабантуй белән бәйле хис-кичерешләрен беләбез. Әлеге сөйләшүгә укучыларны да тартабыз. Алар үз тәэсирләре белән уртаклашырга тиеш булалар. *Сабантуй* сүзенең нәрсә аңлатуын ачыклыйбыз.

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

Алдагы этапта эшләнгәннәргә нигезләнеп, укучылар дәрестә сүзнең нәрсә турында барачагын билгели алачаклар.

**IV. Уку мәсьәләсен адымлап чишү.**

Дәреснең төп өлешендә Ркаил Зәйдулланың «Сабантуй аланында» хикәясе белән танышу күздә тотыла. Әсәрне сыйныфта укыйбыз, яки электрон дәреслектә бирелгән аудиоязмадан укы-

табыз. Видеодәрес материалыннан да файдаланырга мөмкин. Сүзлек эше үткәрелә, *чулпы* сүзенә аңлатма биреп, укучыларда этномәдәни компетенцияләр формалаштырабыз.

Шулай ук бу дәрестә Эльмира Шәрифуллинаның «Сабантуй» шигырен өйрәнү каралган. Әсәрне өйрәнү аны сәнгатьле итеп уку, беренчел тәэсирләрне уртаклашу, сүзлек эше, сорауларга җавап бирү рәвешендә оештырыла. Шигырьне укыганда тагын бер кат Сабантуй бәйрәмендә үткәрелә торган ярыш һәм уеннарны барлыйбыз. Шигырьдә әйтелмәгән уеннарны ачыклыйбыз. Татар көрәшенә аерым тукталып, аның турында укучылардан белгәннәрен сөйләтәбез.

**V. Белемнәрне беренчел ныгыту.**

Әлеге этапта укучылардан Сабантуйда нинди уеннарда катнашуларын сораштырабыз.

Татар мәктәбендә укучылар белән Мансур белән бәйле вакыйга турында укыйбыз (60–61 битләр). Укучыларга Мансурның гамәлләренә бәя бирергә кушыла. Алар сурәтләнгән вакыйгага үз мөнәсәбәтләрен белдерәләр. Биредә укучыларга хәрәмләшү турында сөйләп, аның начар гамәл булуын аңлату мөһим.

**VI. Өй эше бирү.**

Хикәяне, шигырьне сәнгатьле итеп укырга әзерләнергә.

**VII. Рефлексия.**

Дәрестә өйрәнелгәннәргә нәтиҗә ясала.

Бәяләү, үзбәя бирелә.

**Тема**: Әйлән-бәйлән уйныйбыз

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* – күмәклекнең, бердәмлекнең әһәмиятен аңлау.

*Метапредмет нәтиҗәләр* – укытучы ярдәмендә максатны формалаштыру, иптәшләренең җавапларын бәяләү, үзбәя; сәбәп-

нәтиҗә бәйләнешләре урнаштыру; әңгәмәдә катнашу, үз фикерен дәлилләп җиткерә белү.

*Предмет нәтиҗәләр* – Роберт Миңнуллинның «Әйлән-бәйлән» шигыренең эчтәлеген белү, аның буенча сорауларга җавап бирә белү.

**Материал:** Электрон дәреслек: Әдәби уку. 4 нче сыйныф. Ике кисәктә. Икенче кисәк: башлангыч гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен) / Г.Н. Мөхәрләмова, Д.М. Абдуллина. – Казан, 2023 / http://litcorpus.antat.ru/ADABI_UKU/4snf/part2/

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, иллюстрацияләр.

## Дәрес барышы

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

Исәнләшү.

Уңай эмоциональ халәт тудыру.

**II. Актуальләштерү.**

Өй эше тикшерелә. Темага алып керү өчен дәреслек персонажларының диалогын укытабыз.

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

Алдагы этапта эшләнгәннәргә нигезләнеп, укучылар дәрестә сүзнең нәрсә турында барачагын билгели алачаклар.

**IV. Уку мәсьәләсен адымлап чишү.**

Роберт Миңнуллинның «Әйлән-бәйлән» шигыре укыла, сорауларга җавап бирелә. Бу вакытта тормыш белән бәйләнешне истә тотып эшләргә кирәк. Балалардан әйлән-бәйлән уйнаулары турында сораштырабыз.

**V. Белемнәрне беренчел ныгыту.**

Дәреслектә тәкъдим ителгән уеннар белән таныштырабыз. Әлеге һәм башка бу төр уеннарны уйнап каратырга була.

**VI. Өй эше бирү.**

Шигырьне сәнгатьле итеп укырга әзерләнергә.

**VII. Рефлексия.**

Дәрестә өйрәнелгәннәргә нәтиҗә ясала.

Бәяләү, үзбәя бирелә.

**Тема**: Күңелле бәйрәмнәр (кабатлау)

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* – бәйрәмнәрнең әһәмиятен аңлау, аларга хөрмәт хисе белән карау.

*Метапредмет нәтиҗәләр* – уку мәсьәләсен куя белү, иптәшләренең җавапларын бәяләү, үзбәя; гомумиләштерү, нәтиҗә чыгару, проект биремен үтәү; диалог һәм әңгәмә алып бару кагыйдәләрен үтәү, үз фикерен дәлилләп әйтә белү.

*Предмет нәтиҗәләр* – белемнәрне гомумиләштереп системага сала алу.

**Материал:** Электрон дәреслек: Әдәби уку. 4 нче сыйныф. Ике кисәктә. Икенче кисәк: башлангыч гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен) / Г.Н. Мөхәрләмова, Д.М. Абдуллина. – Казан, 2023 / http://litcorpus.antat.ru/ADABI_UKU/4snf/part2/

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, иллюстрацияләр.

**Дәрес барышы**

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

Исәнләшү.

Уңай психологик халәт тудыру.

**II. Актуальләштерү.**

Үткән дәрестә өйрәнелгәннәрне сораштыру.

Хөрмәтле Дәреслекнең дәреслектәге сүзләре белән таныштырабыз. Аларның мәгънәсен ачыклыйбыз.

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

Укытучы укучыларга дәрестә нәрсә эшләячәкләрен җиткерә.

**IV. Белемнәрне ныгыту.**

Дәрестә зур тема кысаларында өйрәнелгән әсәрләрне искә төшерү күздә тотыла. Дәреслектә сораулар бирелгән, аларга җавапларны укучылар укытучы белән бергәләп табалар. Укучы үзенең фикерен җиткергән вакытта, дәлилләр, мисаллар китереп барса, яхшы була.

Хөрмәтле Дәреслек тәкъдим иткән уенны уйнау. Бирелгән сүзләргә карап, нинди бәйрәм турында сүз бару әйтергә тиеш булалар.

Шулай ук Гөлназ китапханәсендәге китаплар белән дә танышу күздә тотыла.

**V. Өйгә эш бирү.**

«Безнең бәйрәмнәребез» дигән темага проект эше әзерләргә.

**VI. Рефлексия.**

Дәрестә өйрәнелгәннәргә нәтиҗә ясала.

Бәяләү, үзбәя бирелә.

**Тема**: Май килә

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* – табигатьнең матурлыгын һәм кеше күңелендәге шатлык хисләренең бер-берсен тулыландыруын аңлау.

*Метапредмет нәтиҗәләр* – уку мәсьәләсен куя белү, иптәшләренең җавапларын бәяләү; мәгълүмат алу, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләре урнаштыру; диалог һәм әңгәмә алып бару кагыйдәләрен үтәү, үз фикерен әйтә белү.

*Предмет нәтиҗәләр* – Роберт Миңнуллинның «Май килә» шигыренең эчтәлеген аңлау, аның буенча сорауларга җавап бирә белү.

**Материал:** Электрон дәреслек: Әдәби уку. 4 нче сыйныф. Ике кисәктә. Икенче кисәк: башлангыч гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучы-

лар өчен) / Г.Н. Мөхәрләмова, Д.М. Абдуллина. – Казан, 2023 / http://litcorpus.antat.ru/ADABI_UKU/4snf/part2/

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, иллюстрацияләр.

## Дәрес барышы

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

Укучылар белән исәнләшү, дәрескә әзерлекләрен сораштыру, дәрескә оештыру.

**II. Актуальләштерү.**

Өй эшен тикшерү рәвешендә үткәрелә ала.

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

Дәреслек герое Алмазның репликасы аша хәл ителә ала. Укучылар сөйләшүнең май ае турында булуын билгели алалар.

**IV. Уку мәсьәләсен адымлап чишү.**

Гөлназның репликасына җавап рәвешендә туган сөйләшү май ае һәм бәйрәмнәр темасын берләштерә, бу хакта сөйләшүгә ачкыч ролен үти.

Роберт Миңнуллинның «Май килә» шигырен уку, сүзлек белән эш сорауларга җаваплар бирү, бер яктан, шигырьнең эчтәлеген аңлау, аны әдәби текст буларак анализлауга китерә. Икенче яктан, укучыга язның беренче ае – май турындагы фикерләр белән уртаклашу бу айның үзенчәлеген һәм бәйрәмнәрен аңларга ярдәм итә.

Май – чыннан да гаҗәеп матур, дөньяны чәчәкләргә күмә, соклангыч матурлык бүләк итә торган ай. Табигатьнең яңаруы күңелләрне дә уята, хисләндерә. Ә шагыйрь шушы матурлыкның кешеләр күңелен шатлык белән тутырган Җиңү бәйрәме алып килүе белән дә бәйле булуын күрсәтә. Йөзләрдәге балку, күңелләрдәге шатлык хисен ул шуның белән бәйләп аңлата. Шигырьдәге шул хисне ачуга игътибар бирү кирәк. Моның өчен Бөек Ватан сугышын, аның халкыбызга китергән авырлыгын, кешеләрнең сугыш тәмамлануны ничек көтүләрен аңлату әһәмиятле. Май аенда табигать матурлыгының Җиңү көне белән кушылуы ке-

шеләр күңелендәге шатлыкны икеләтә арттыра. Дөнья матурлыгын, тормыш рәхәтен тоярга өйрәтә.

Тирәнтен өйрәнүчеләр үзе сугышта катнашкан язучы Кави Нәҗминең «Дан сиңа, илем!» исемле сугыш һәм җиңү язы турындагы хикәясе белән танышканнан соң, Җиңү көненең никадәр якты бәйрәм булуы, кеше рухында нинди хисләр тудыруы турында фикер алышу үткәрелә. Текстның тәэсирлелеге, хикәяләүче хисләренең, шатлык һәм горурлыгының чиксезлеген аңларга ярдәм итә торган җөмләләргә игътибар иттерү кирәк.

**V. Белемнәрне беренчел ныгыту.**

Дәреслек геройларының 103 биттәге әңгәмәсенә кушылып, май аендагы бәйрәмнәр турында сөйләшү, бу бәйрәмнәрнең тарихи җирлеген билгеләү дәрестә алган белемнәрне ныгытырга, истә калдырырга ярдәм итә. 1 май бәйрәме турында өстәмә мәгълүмат бирү дә урынлы булыр.

**VI. Өй эше бирү.**

Шигырьне сәнгатьле итеп укырга.

**VII. Рефлексия.**

Дәрестә өйрәнелгәннәргә нәтиҗә ясала.

Бәяләү, үзбәя бирелә.

**Тема**: Афәт килгән илгә

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* – Бөек Ватан сугышының ил халкына күпме авырлык, михнәт китерүен аңлау, Бөек Җиңүнең кадерен белү.

*Метапредмет нәтиҗәләр* – уку мәсьәләсен кую, иптәшләренең җавапларын бәяләү, үзбәя; сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләре урнаштыру; әңгәмәдә катнашу, үз фикерен дәлилләп җиткерә белү.

*Предмет нәтиҗәләр* – Рафис Корбанның «Җиңү бәйрәме» шигыренең эчтәлеген белү, аның буенча сорауларга җавап бирә алу.

**Материал:** Электрон дәреслек: Әдәби уку. 4 нче сыйныф. Ике кисәктә. Икенче кисәк: башлангыч гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен) / Г.Н. Мөхәрләмова, Д.М. Абдуллина. – Казан, 2023 / http://litcorpus.antat.ru/ADABI_UKU/4snf/part2/

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, иллюстрацияләр, видеоролик.

### Дәрес барышы

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

Исәнләшү.

Уңай эмоциональ халәт тудыру.

**II. Актуальләштерү.**

Өй эше тикшерелә: шигырь сәнгатьле итеп укыла. Темага алып керү өчен дәреслек персонажларының әңгәмәсен укытабыз. Диалогның дәвамы буларак, Энҗе Мөэминованың дәреслектә бирелгән «Моңсу бәйрәм» шигыре белән таныштырып, фикер алышу үткәрәбез. Укучылар Җиңү бәйрәменең әһәмиятен аңларга тиеш булалар.

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

Алдагы этапта эшләнгәннәргә нигезләнеп, укучылар дәрестә сүзнең нәрсә турында барачагын билгели алачаклар.

**IV. Уку мәсьәләсен адымлап чишү.**

Дәрестә өйрәнү өчен Рафис Корбанның «Җиңү бәйрәме» шигыре тәкъдим итәлә. Әсәрне сыйныфта укыйбыз, яки электрон дәреслектәге аудиоязманы тыңлыйбыз. Видеодәрес материалыннан да файдаланырга мөмкин. Сорауларга җаваплар алганда, аларның тормыш белән бәйләнешле булуын истә тотып эшләргә кирәк.

**V. Белемнәрне беренчел ныгыту.**

Укучылар белән Җиңү бәйрәмен ничек үткәрүләре турында әңгәмә оештырырга мөмкин.

**VI. Өй эше бирү.**

Шигырьне ятларга.

**VII. Рефлексия.**

Дәрестә өйрәнелгәннәргә нәтиҗә ясала.

Бәяләү, үзбәя бирелә.

**Тема**: Алтын хәрефләр белән язылган исемнәр

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* – батырлыкның онытылмавын, үлемсезлеген аңлау.

*Метапредмет нәтиҗәләр* – уку мәсьәләсен куя белү, иптәшләренең җавапларын бәяләү; мәгълүмат алу, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләре урнаштыру; әңгәмәдә катнашу, үз фикерен әйтә белү.

*Предмет нәтиҗәләр* – Мәдинә Маликованың «Һәйкәл янында» хикәясененең, Вәсимә Хәйруллинаның «Билгесез солдат» шигыренең эчтәлеген аңлау, төп идеясен билгеләү, әсәр буенча сорауларга җавап бирә белү.

**Материал:** Электрон дәреслек: Әдәби уку. 4 нче сыйныф. Ике кисәктә. Икенче кисәк: башлангыч гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен) / Г.Н. Мөхәрләмова, Д.М. Абдуллина. – Казан, 2023 / http://litcorpus.antat.ru/ADABI_UKU/4snf/part2/

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, иллюстрацияләр, видеоролик.

**Дәрес барышы**

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

Укучылар белән исәнләшү, дәрескә әзерлекләрен сораштыру, дәрескә оештыру.

**II. Актуальләштерү.**

Өй эшен тикшерү: алдагы дәрестә ятларга бирелгән шигырьне тыңлау.

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

Уку мәсьәләсен куюда дәреслек персонажларының әңгәмәсе ярдәм итә алыр. Шуның буенча укучылар бу дәрестә сугыш батырлары турында сөйләшәчәкләрен билгелиләр.

**IV. Уку мәсьәләсен адымлап чишү.**

Дәреснең төп өлешендә Мәдинә Маликованың «Һәйкәл янында» хикәясе белән танышу күздә тотыла. Әсәрне сыйныфта укыйбыз, яки электрон дәреслектә бирелгән аудиоязманы тыңлатабыз. Видеодәрес материалыннан да файдаланырга мөмкин. Текст укылганнан соң, сорауларга җавап алына.

Алга таба дәресне Вәсимә Хәйруллинаның «Билгесез солдат» шигырен уку, сүзлек белән эш, сорауларга җавап бирү рәвешендә дәвам итеп була. Бу –дәреснең темасын үзләштерүгә һәм сөйләшүне киңәйтүгә юл ача. Әлеге этапны үткәч, китапның 77 битендәге рәсемгә игътибар итәргә, Мәңгелек ут турында сөйләшергә мөмкин. Аның символик мәгънәсенә, зур эчтәлекле булуына тукталу да урынлы булыр. Мәңгелек ут – туган ил азатлыгын яклап батырларча һәләк булганнарның истәлеген мәңгеләштерү максатыннан кабызылган гел янып тора торган ут. Безнең илебездә ул иң беренче тапкыр 1957 елның 9 маенда Тула өлкәсенең Беренче май бистәсендә, Җиңү бәйрәмен билгеләп үткәндә, Бөек Ватан сугышында һәлак булганнар истәлегенә кабызыла. Әмма ул гел янып тормый, бәйрәмнәрдә генә кабызыла торган була. 1967 елда Мәскәүдә Кремль диварлары янында Билгесез солдат кабере мемориалы булдырылганнан соң, 8 май көнне Мәңгелек ут кабызыла һәм ул туктаусыз янып торучы ут булып кала.

Әлеге яңалыклар белән таныштырганнан соң, Туган ил азатлыгы, аны яклап көрәшүнең изге бурыч булуын аңлату һәм укучылар белән сөйләшү оештырыла ала.

**V. Белемнәрне беренчел ныгыту.**

Дәреслектә Алмазның репликасындагы *Исемең билгесез, батырлыгың – үлемсез* гыйбарәсен кабат искә төшереп, халыкның

үз батырларын онытмавын, күп еллар үтсә дә, хөрмәт белән хәтерендә саклавын аңларга ярдәм итә торган сораулар ярдәмендә йомгаклауга чыгарга мөмкин.

**VI. Өйгә эше бирү.**

Мәдинә Маликованың «Һәйкәл янында» хикәясен, Вәсимә Хәйруллинаның «Билгесез солдат» шигырен сәнгатьле итеп укырга.

**VII. Рефлексия.**

Дәрестә өйрәнелгәннәргә нәтиҗә ясала.

Бәяләү, үзбәя бирелә.

**Тема**: Сугыш турында сөйләшә картлар

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* – сугыш һәм тыл ветераннарына хөрмәт хисе булу.

*Метапредмет нәтиҗәләр* – уку мәсьәләсен куя белү, иптәшләренең җавапларын бәяләү; сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләре урнаштыру; әңгәмәдә катнашу, үз фикерен әйтә белү.

*Предмет нәтиҗәләр* – Ренат Харисның «Сугыш турында сөйләшә картлар» шигыренең, Фоат Садриевның «Бабам сугышта булган» хикәясенең эчтәлеген аңлау, төп идеясен билгеләү, әсәр буенча сорауларга җавап бирә белү.

**Материал:** Электрон дәреслек: Әдәби уку. 4 нче сыйныф. Ике кисәктә. Икенче кисәк: башлангыч гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен) / Г.Н. Мөхәрләмова, Д.М. Абдуллина. – Казан, 2023 / http://litcorpus.antat.ru/ADABI_UKU/4snf/part2/

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, иллюстрацияләр.

## Дәрес барышы

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

Укучылар белән исәнләшү, дәрескә әзерлекләрен сораштыру, дәрескә оештыру.

**II. Актуальләштерү.**

Өй эшен тикшерү: үткән тема буенча сорауларга җавап бирү.

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

Уку мәсьәләсен куюга дәреслек геройларының әңгәмәсе ярдәм итә алыр. Шуның буенча укучылар бу дәрестә нәрсә турында сөйләшәчәкләрен билгелиләр.

**IV. Уку мәсьәләсен адымлап чишү.**

Дәреснең бу өлешендә ике әсәрне өйрәнү планлаштырылган. Иң элек Ренат Харисның «Сугыш турында сөйләшә картлар» шигыре укыла, сүзлек эше башкарыла. Сорауларга җавап биргәндә, сугыш ветераннарына хас сыйфатларга игътибар иттерәбез. Укучылар сабырлык, тыйнаклык, батырлык кебек сыйфаларны күрсәтә алырлар. Сугыш юлларыннан узган ветераннар саны инде хәзер елдан-ел кими баруын ассызыклап, аларга бүген аеруча зур кадер-хөрмәт, ихтирам таләп ителүен аңлатабыз. Фронт өчен фидакяр хезмәт куйган тыл ветераннары, сугыш еллары афәтен кичергән балалар турында да мәгълүмат бирергә кирәк.

Фоат Садриевның «Тургай» исемле повестеннан алынган «Бабам сугышта булган» исемле күләме ягыннан зур булмаган хикәясен өйрәнгәндә, картларның сугышка мөнәсәбәтен билгеләп була. Сугыш – фаҗига, әмма укучылар туган ил азатлыгын яклап көрәшүнең мактауга лаек зур батырлык икәнен дә аңлап калырга тиеш.

Дәрестә дәреслектәге иллюстрацияләргә дә игътибарны юнәлтеп, сөйләм телен үстерү өстендә эшләп була.

**V. Өйгә эше бирү.**

Хикәяләрне укырга, эчтәлеген сөйләргә әзерләнергә, «Җиңү бәйрәме» дип исемләнгән бүлекне кабатлау өчен булган сорауларга җаваплар бирергә.

**VI. Рефлексия.**

Дәрестә өйрәнелгәннәргә нәтиҗә ясала.

Бәяләү, үзбәя бирелә.

**Тема**: Җиңү бәйрәме (кабатлау).

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* – туган илгә мәхәббәт, үз халкыңны яратырга кирәклекне аңлау.

*Метапредмет нәтиҗәләр* – уку мәсьәләсен куя белү, иптәшләренең җавапларын бәяләү; сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләре урнаштыру, гомумиләштерә һәм нәтиҗә ясый белү, тамга-символик чараларны куллану; әңгәмәдә катнашу, үз фикерен дәлилләп әйтә белү.

*Предмет нәтиҗәләр* – «Җиңү бәйрәме» дип аталган зур темада үзләштерелергә тиешле әһәмиятле өлешләрне истә калдыру, сорауларга җавап бирә белү.

**Материал:** Электрон дәреслек: Әдәби уку. 4 нче сыйныф. Ике кисәктә. Икенче кисәк: башлангыч гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен) / Г.Н. Мөхәрләмова, Д.М. Абдуллина. – Казан, 2023 / http://litcorpus.antat.ru/ADABI_UKU/4snf/part2/

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, иллюстрацияләр.

## Дәрес барышы

### I. Оештыру-мотивлаштыру.

Укучылар белән исәнләшү, дәрескә әзерлекләрен сораштыру, дәрескә оештыру.

### II. Актуальләштерү.

Өй эшен тикшерү рәвешендә үткәрелә ала.

### III. Уку мәсьәләсен кую.

Укучылар алдагы сөйләшүдән, зур теманың соңгы дәресе буларак, кабатлау, үткәннәрне искә төшерү дәресе икәнлеген билгели алалар.

### IV. Белемнәрне ныгыту.

Кабатлауны төрлечә оештырырга мөмкин. Анда һәр укучы катнашырга (димәк, сорауларның авырлары да һәм җиңелрәкләре

дә булсын), дәрес формасы да кызыклы булырга тиеш. Беркадәр ярыш төсмере бирелсә, бигрәк тә яхшы.

Мәсәлән, алдан карточкалар әзерләп, аларга бу бүлектә укылган әсәрләрнең исемнәрен һәм авторларын язып куярга була. Һәр партада утырган (төркемдә булган) укучылар бер карточканы алып, бу әсәр турында белгәннәрен әйтәләр (башка төркемнәр дә өсти ала). Бу укылган әсәрләрне тиз генә искә төшерергә ярдәм итә. Шул ук алым белән аерым әсәрнең темасын, төп фикерен искә төшерергә, бирелгән өзекнең кайсы әсәрдән булуын ачыкларга һ.б. биремнәрне үтәргә була.

Дәреслектәге рәсемнәрне экранга чыгарып, аның кайсы авторның нинди әсәре булуын ачыклатырга, яки укучыларга алдан ук төрле әсәрләргә рәсем ясарга кушып, күргәзмә оештырырга һәм алар буенча сөйләшү уткәрергә мөмкин.

Укучыларның аерым сүзләрнең мәгънәсен хәтердә калдыруларын ачыклау өчен, сорауларны да төрлечә әзерләргә була.

Биремнәр бик төрле булырга мөмкин, әмма кабатлау үтелгән материалның иң әһәмиятле өлешләрен укучының хәтеренә сеңдеререргә булышырга тиеш.

**V. Рефлексия.**

Дәрестә өйрәнелгәннәргә нәтиҗә ясала.

Бәяләү, үзбәя бирелә.

Учебное издание

**Мухарлямова** Гульназ Нурфатовна
**Абдуллина** Дилария Маратовна

ЛИТЕРАТУРНОЕ ЧТЕНИЕ

**4 класс**

Методическое пособие
для преподавателей образовательных организаций
начального общего образования, работающих
с учащимися, изучающими татарский язык как родной

На татарском языке

Уку-укыту басмасы

**Мөхәрләмова** Гөлназ Нурфат кызы
**Абдуллина** Диләрия Марат кызы

ӘДӘБИ УКУ

**4 нче сыйныф**

Методик әсбап
Башлангыч гомуми белем бирү оешмаларында
татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар белән
эшләүче укытучылар өчен

Мөхәррире *Л.Г. Шәрифуллина*
Рәссамы *Д.Л. Нәүрузова*
Компьютерда биткә салучысы *Э.Ф. Нурмөхәммәтова*

Подписано в печать с оригинал-макета 10.04.2023.
Формат 60 х 84 1/16. Бумага офсетная.